Екатериновка авыл җирлеге чиге Чыты авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 18 нче тоташу ноктасыннан алып 400 м төньяк-көнбатышка таба «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Питрәч участок урманчылыгындагы 106 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары 100 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Мәскәү — Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 107 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 500 м көньякка таба, көньяк чиге буйлап 700 м көнбатышка таба һәм көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 200 м төньякка таба, 50 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, алга таба 107 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м бара, 107 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 100 м уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м көньяк-көнбатышка таба, 100 м төньяк-көнбатышка таба бара, 107 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 300 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м, сынык сызык ясап, төньякка таба 107 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 300 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м уза, 107 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Мәскәү — Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнбатыш чигенә кадәр 20 м уза, алга таба 2,7 км төньяк-көнбатышка таба әлеге

автомобиль юлына бүлеп бирелгән полоса чиге буйлап Екатериновка, Чыты һәм Күн авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Екатериновка авылыннан 2,7 км төньякта урнашкан 24 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Екатериновка авыл җирлеге чиге Күн авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 24 нче тоташу ноктасыннан алып 1,1 км көнбатышка таба Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк чиге буйлап уза, аннары «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Питрәч участок урманчылыгындагы 99 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 1,1 км төньякка таба, төньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,7 км көньяк-көнбатышка таба һәм көньяк-көнбатыш чиге буйлап 300 м көньяк-көнчыгышка таба Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чигенә кадәр бара, алга таба 3,5 км көньяк-көнбатышка таба әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полоса чиге буйлап Екатериновка, Күн һәм Шәле авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Нептун авылыннан 1,6 км төньяк-көнбатышта урнашкан 27 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Екатериновка авыл җирлеге чиге Шәле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 27 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, 350 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, кибеп баручы инешкә кадәр уза, аннары кибеп баручы инеш агымы буенча 650 м аска таба бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,3 км, «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Питрәч участок урманчылыгындагы 146 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, кибеп баручы инешкә кадәр 350 м уза, әлеге инеш агымы буенча 750 м аска таба бара, аннары көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 200 м, 146 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 450 м бара, алга таба, сынык сызык ясап, 1,3 км көньяк-көнчыгышка таба 146 нчы, 153 нче урман кварталларының көнчыгыш һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап Екатериновка, Шәле авыл җирлекләре һәм Балык Бистәсе муниципаль районы чикләре тоташкан урында Яңа Никольский авылыннан 2,0 км көньякта урнашкан 25 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Екатериновка авыл җирлеге чиге Балык Бистәсе муниципаль районы белән чиктәш җирдә 25 нче тоташу ноктасыннан

алып Питрәч муниципаль районы чиге буйлап 49 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.»;

2) 7 – 24 нче кушымталарны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Питрәч муниципаль районы»<br>муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы<br>муниципаль берәмлекләрнең территорияләре<br>чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»<br>Татарстан Республикасы Законына<br>7 нче кушымта

**Питрәч муниципаль районының «Кибәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Кибәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Питрәч муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Кибәч авыл җирлеге Кавал, Керәшен Сәрдәсе, Татар Казысы, Пановка, Пимәр, Татар Тау Иле, Чыты һәм Янсуар авыл җирлекләре белән чиктәш.

Кибәч авыл җирлеге чиге Кавал авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Кибәч, Кавал һәм Пановка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Чуча авылыннан 4,0 км көньяк-көнбатышта урнашкан 7 нче тоташу ноктасыннан алып 1,4 км төньяк-көнчыгышка таба Казан – Шәмәрдән автомобиль юлы буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба «Казан – Шәмәрдән» – Кибәч автомобиль юлы буйлап 1,2 км, «Казан – Шәмәрдән» – Кибәч автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны аның көнчыгыш чигенә кадәр кисеп үтеп, «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Питрәч участок урманчылыгындагы 23 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 950 м бара, алга таба автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның әлеге чиге буенча 2,3 км көньякка таба бара, аннары көнчыгышка таба, юл буендагы урман полосасын кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 23 нче, 24 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,4 км көньяк-көнчыгышка таба уза, 800 м

көньяк-көнбатышка таба 26 нчы урман кварталы буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 1,4 км көнбатышка таба 28 нче, 27 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап уза, алга таба 1,2 км көньякка таба 27 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап бара, аннары 1,3 км көнчыгышка таба 27 нче, 28 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап уза, 200 м төньяк-көнчыгышка таба 28 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, сынык сызык ясап, 550 м көньяк-көнчыгышка таба, Кавал елгасын һәм аның текә ярларын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,0 км көнчыгышка таба 29 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап уза, 250 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, алга таба, сынык сызык ясап, 1,4 км көньяк-көнчыгышка таба 29 нчы, 30 нчы урман кварталларының көньяк һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап уза, аннары 250 м төньяк-көнчыгышка таба 30 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап Кибәч, Кавал һәм Янсуар авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Талкыш авылыннан 2,2 км төньяк-көнбатышта урнашкан 15 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Кибәч авыл җирлеге чиге Янсуар авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 15 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 850 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буенча, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Кибәч, Янсуар һәм Татар Казысы авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Талкыш авылыннан 900 м көнбатышта урнашкан 14 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Кибәч авыл җирлеге чиге Татар Казысы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 14 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Питрәч участок урманчылыгындагы 34 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 700 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м, 34 нче урман кварталы буйлап 100 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м, 34 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м, 34 нче урман кварталы буйлап 150 м һәм аның көнбатыш чиге буйлап 250 м бара, аннары 34 нче урман кварталы буйлап 200 м көньякка таба һәм аның көньяк-көнбатыш чиге буйлап 250 м көньяк-көнчыгышка таба бара, сынык сызык ясап, 50 м көньякка таба 179 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 500 м көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 500 м көнбатышка таба уза, алга таба 100 м көньяк-көнбатышка таба 37 нче урман

кварталы буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 800 м көньяк-көнбатышка таба һәм 100 м төньяк-көнбатышка таба, яр буе агач-куак полосасын кисеп үтеп, Мишә елгасына кадәр бара, 10 м Мишә елгасы буенча Кибәч, Татар Казысы һәм Керәшен Сәрдәсе авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Казиле авылыннан 2,0 км төньяк-көнбатышта әлеге елгада урнашкан 50 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Кибәч авыл җирлеге чиге Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 50 нче тоташу ноктасыннан алып Мишә елгасы агымы буенча 11,6 км аска таба Кибәч, Керәшен Сәрдәсе һәм Чыты авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кибәч авылыннан 2,0 км көньяк-көнбатышта урнашкан 19 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Кибәч авыл җирлеге чиге Чыты авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 19 нчы тоташу ноктасыннан алып Мишә елгасы агымы буенча 3,4 км аска таба уза, алга таба әлеге елга буенча 10 м төньякка таба, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м көнчыгышка таба һәм, сынык сызык ясап, 200 м төньяк-көнбатышка таба бара, «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Питрәч участок урманчылыгындагы 177 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 350 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м, 173 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап, чокырларны кисеп үтеп, 200 м уза, 1,4 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, алга таба 850 м көньяк-көнбатышка таба урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап Кибәч, Чыты һәм Пимәр авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Чыты авылыннан 2,8 км төньякта урнашкан 20 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Кибәч авыл җирлеге чиге Пимәр авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 20 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, 5,9 км төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба 50 м төньяк-көнчыгышка таба урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап Кибәч, Пимәр һәм Татар Тау Иле авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Пановка авылыннан 2,2 км көньяк-көнбатышта урнашкан 21 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Кибәч авыл җирлеге чиге Татар Тау Иле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 21 нче тоташу ноктасыннан алып 150 м көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр уза, әлеге инеш агымы буенча 2,5 км аска таба Кибәч, Татар Тау Иле һәм Пановка авыл җирлекләре чикләре то-

ташкан урында Новоселок авылының көньяк-көнбатыш чигендә урнашкан 8 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Кибәч авыл җирлеге чиге Пановка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 7 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 50 м Казан – Шәмәрдән автомобиль юлы буйлап, 200 м профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 100 м уза, алга таба көнбатышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр бара, инеш агымы буенча 100 м аска таба, 200 м буаның уң яры буенча уза, инеш агымы буенча 350 м аска таба аның Сеинка елгасы белән кушылган җиренә кадәр бара, әлеге инеш агымы буенча 250 м өскә таба уза, алга таба, сынык сызык ясап, 250 м төньяк-көнбатышка таба, текә ярны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 8 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Питрәч муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен
билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
8 нче кушымта

**Питрәч муниципаль районының «Кибәк Иле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Кибәк Иле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Питрәч муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Кибәк Иле авыл җирлеге Белкино, Надеждино авыл җирлекләре, Арча һәм Биектау муниципаль районнары белән чиктәш.

Кибәк Иле авыл җирлеге чиге Арча муниципаль районы белән чиктәш җирдә Кибәк Иле, Белкино авыл җирлекләре һәм Арча муниципаль районы чикләре тоташкан урында Кудаш Иле авылыннан 800 м төньяк-көнчыгышта Норма елгасында урнашкан 2 нче тоташу ноктасыннан алып Питрәч муниципаль районы чиге буйлап Кибәк Иле авыл җирлеге, Арча һәм Биектау муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Кибәк Иле

авылыннан 4,4 км төньяк-көнбатышта урнашкан 1 нче (46 нчы) тоташу ноктасына кадәр уза.

Кибәк Иле авыл җирлеге чиге Биектау муниципаль районы белән чиктәш җирдә 1 нче (46 нчы) тоташу ноктасыннан алып Питрәч муниципаль районы чиге буйлап Кибәк Иле, Надеждино авыл җирлекләре һәм Биектау муниципаль районы чикләре тоташкан урында Урта Ия авылыннан 2,4 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 46 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Кибәк Иле авыл җирлеге чиге Надеждино авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 46 нчы тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 700 м «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Ленин участок урманчылыгындагы 46 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,6 км көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 1,1 км көньяк-көнчыгышка таба бара, сынык сызык ясап, 300 м «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Питрәч участок урманчылыгындагы 11 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 800 м көньякка таба, сынык сызык ясап, 2,0 км төньяк-көнчыгышка таба, 100 м көньяк-көнчыгышка таба уза, 100 м агач-куак массивы буйлап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Кибәк Иле, Надеждино һәм Белкино авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Урта Ия авылыннан 2,5 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 3 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Кибәк Иле авыл җирлеге чиге Белкино авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 3 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 30 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м сазлыкның төньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 2,2 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Белкино – Кибәк Иле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, Шира елгасына кадәр уза, аннары Шира елгасы агымы буенча 3,1 км аска таба аның Норма елгасына койган җиренә кадәр бара, әлеге елга агымы буенча 5,7 км өскә таба 2 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Питрәч муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен
билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
9 нчы кушымта

**Питрәч муниципаль районының «Кавал авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Кавал авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Питрәч муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Кавал авыл җирлеге Кибәч, Пановка, Янсуар авыл җирлекләре һәм Теләче муниципаль районы белән чиктәш.

Кавал авыл җирлеге чиге Пановка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Кавал, Пановка авыл җирлекләре һәм Теләче муниципаль районы чикләре тоташкан урында Урывкино авылыннан 1,4 км төньякта Сеинка елгасында урнашкан 6 нчы тоташу ноктасыннан алып Сеинка елгасы агымы буенча 3,2 км аска таба буага кадәр уза, 350 м көньякка таба әлеге буа буйлап бара, Сеинка елгасы агымы буенча 4,8 км аска таба уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 350 м көньяк-көнчыгышка таба һәм, сынык сызык ясап, 1,3 км көньяк-көнбатышка таба Кавал, Пановка һәм Кибәч авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Чуча авылыннан 4,0 км көньяк-көнбатышта урнашкан 7 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Кавал авыл җирлеге чиге Кибәч авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 7 нче тоташу ноктасыннан алып 1,4 км төньяк-көнчыгышка таба Казан – Шәмәрдән автомобиль юлы буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба «Казан – Шәмәрдән» – Кибәч автомобиль юлы буйлап 1,2 км, «Казан – Шәмәрдән» – Кибәч автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны аның көнчыгыш чигенә кадәр кисеп үтеп, «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Питрәч участок урманчылыгындагы 23 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 950 м бара, алга таба автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның әлеге чиге буенча 2,3 км көньякка таба бара, аннары көнчыгышка таба, юл буендагы ур-

ман полосасын кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 23 нче, 24 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,4 км көньяк-көнчыгышка таба уза, 800 м көньяк-көнбатышка таба 26 нчы урман кварталы буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 1,4 км көнбатышка таба 28 нче, 27 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап уза, алга таба 1,2 км көньякка таба 27 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап бара, аннары 1,3 км көнчыгышка таба 27 нче, 28 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап уза, 200 м төньяк-көнчыгышка таба 28 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, сынык сызык ясап, 550 м көньяк-көнчыгышка таба, Кавал елгасын һәм аның текә ярларын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,0 км көнчыгышка таба 29 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап уза, 250 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, алга таба, сынык сызык ясап, 1,4 км көньяк-көнчыгышка таба 29 нчы, 30 нчы урман кварталларының көньяк һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап уза, аннары 250 м төньяк-көнчыгышка таба 30 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап Кавал, Кибәч һәм Янсуар авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Талкыш авылыннан 2,2 км төньяк-көнбатышта урнашкан 15 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Кавал авыл җирлеге чиге Янсуар авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 15 нче тоташу ноктасыннан алып 950 м төньяк-көнчыгышка таба «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Питрәч участок урманчылыгындагы 30 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көнчыгышка таба 166 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м бара, 166 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап 200 м уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 1,5 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,0 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 31 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 300 м бара, аннары төньякка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 750 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 30 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Кавал, Янсуар авыл җирлекләре һәм Теләче муниципаль районы чикләре тоташкан урында Кавал авылыннан 1,5 км көнчыгышта урнашкан 11 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Кавал авыл җирлеге чиге Теләче муниципаль районы белән чиктәш җирдә 11 нче тоташу ноктасыннан алып Питрәч муниципаль районы чиге буйлап 6 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

«Питрәч муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен
билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
10 нчы кушымта

**Питрәч муниципаль районының «Күн авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Күн авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Питрәч муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Күн авыл җирлеге Екатериновка, Ленино-Кокушкино, Питрәч, Пимәр, Чыты һәм Шәле авыл җирлекләре белән чиктәш.

Күн авыл җирлеге чиге Пимәр авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Күн, Пимәр һәм Ленино-Кокушкино авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Олы Норма авылыннан 2,2 км көнбатышта Мишә елгасында урнашкан 31 нче тоташу ноктасыннан алып Мишә елгасы агымы буенча 1,3 км өскә таба, әлеге елга буенча 10 м көнчыгышка таба уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба, яр буе агач-куак массивын кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м агач-куак массивы буйлап бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 30 м агач-куак массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 250 м көньяк-көнчыгышка таба, 100 м агач-куак массивы буйлап, текә ярны кисеп үтеп, Мишә елгасына кадәр уза, әлеге елга буенча 10 м һәм аның агымы буенча 300 м өскә таба уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 10 м елга буенча, елганың текә сул ярын кисеп үтеп, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 450 м төньяк-көнчыгышка таба, елганың текә уң ярын кисеп үтеп, Мишә елгасына кадәр бара, Мишә елгасы буенча 20 м һәм аның агымы буенча 700 м өскә таба әлеге елга ермагы тамагына кадәр уза, әлеге ермак буенча аның агымы буенча 500 м өскә таба бара, төньяк-көнбатышка таба 100 м күл буенча уза, Мишә елгасы ермагы буйлап аның агымы буенча 800 м өскә таба бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м көньяк-көнбатышка таба һәм 100 м көньяк-көнчыгышка таба бара, 50 м агач-куак массивы буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м сазлыкның

көньяк-көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 40 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 200 м, 50 м сазлыкның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сазлыкны һәм яр буе агач-куак массивын кисеп үтеп, Мишә елгасы ермагына кадәр уза, аннары әлеге ермак агымы буенча 200 м өскә таба уза, күлнең көнбатыш чиге буйлап 50 м бара һәм кабат әлеге ермак агымы буенча 1,5 км өскә таба Мишә елгасының төп үзәненә кадәр бара, әлеге елга агымы буенча 2,5 км өскә таба Күн, Пимәр һәм Чыты авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Әлбәдән авылыннан 800 м көньяк-көнчыгышта Мишә елгасында урнашкан 23 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Күн авыл җирлеге чиге Чыты авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 23 нче тоташу ноктасыннан алып Мишә елгасы ермагы агымы буенча 750 м өскә таба уза, аннары, сынык сызык ясап, 550 м көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, әлеге инеш агымы буенча, Питрәч — Чыты — Янсуар автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 4,5 км өскә таба уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 2,6 км көньяк-көнчыгышка таба, 600 м көньяк-көнбатышка таба бара, 100 м урман утыртмаларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м урман утыртмалары буйлап уза, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м агач-куак массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 700 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Мәскәү — Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, Күн, Чыты һәм Екатериновка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Екатериновка авылыннан 2,7 км төньякта урнашкан 24 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Күн авыл җирлеге чиге Екатериновка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 24 нче тоташу ноктасыннан алып 1,1 км көнбатышка таба Мәскәү — Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк чиге буйлап уза, аннары «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Питрәч участок урманчылыгындагы 99 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 1,1 км төньякка таба, төньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,7 км көньяк-көнбатышка таба һәм көньяк-көнбатыш чиге буйлап 300 м көньяк-көнчыгышка таба Мәскәү — Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чигенә кадәр бара, алга таба 3,5 км көньяк-көнбатышка таба әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полоса чиге буйлап Күн, Екатериновка һәм Шәле авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында

Нептун авылыннан 1,6 км төньяк-көнбатышта урнашкан 27 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Күн авыл җирлеге чиге Шәле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 27 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 40 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м һәм, чокырларны кисеп үтеп, 1,6 км төньяк-көнбатышка таба, 900 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 450 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, алга таба төньякка таба, сынык сызык ясап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, төньяк-көнчыгышка таба 150 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, «Мәскәү — Уфа» — Күн автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 400 м «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Питрәч участок урманчылыгындагы 94 нче, 92 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 92 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 50 м бара, әлеге урман кварталы буйлап 400 м көньяк-көнбатышка таба уза, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 92 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап 100 м бара, алга таба, сынык сызык ясап, 550 м көньякка таба 94 нче урман кварталы буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 94 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 800 м бара, әлеге урман кварталы буйлап 400 м һәм аның көнбатыш чиге буйлап 100 м, Мәскәү — Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 93 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м уза, әлеге урман кварталы буенча 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 40 м бара, алга таба төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м, 93 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м уза, Мәскәү — Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кабат кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 93 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буйлап, сынык сызык ясап, 400 м бара, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары төньякка таба 93 нче, 91 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 700 м бара, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 91 нче, 87 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап,

канауны кисеп үтеп, 1,8 км уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 85 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 400 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, 79 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,1 км Күн, Шәле һәм Питрәч авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Олан Иле авылыннан 2,1 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 29 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Күн авыл җирлеге чиге Питрәч авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Күн, Питрәч һәм Ленино-Кокушкино авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Олы Норма авылыннан 2,6 км көнбатышта Мишә елгасында урнашкан 30 нчы тоташу ноктасыннан алып Мишә елгасы агымы буенча 5,1 км аска таба уза, аннары көньякка таба 20 м әлеге елга буенча, сынык сызык ясап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Питрәч участок урманчылыгындагы 176 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап 100 м бара, 77 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш һәм төньяк чикләре буйлап 1,1 км төньяк-көнбатышка таба уза, 76 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,4 км көньяк-көнбатышка таба, Питрәч – Чыты – Янсуар автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 600 м 76 нчы урман кварталы буйлап 29 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Күн авыл җирлеге чиге Ленино-Кокушкино авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 30 нчы тоташу ноктасыннан алып Мишә елгасы агымы буенча 450 м өскә таба 31 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Питрәч муниципаль районы»<br>муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы<br>муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен<br>билгеләү һәм аларның статусы турында»<br>Татарстан Республикасы Законына<br>11 нче кушымта

## Питрәч муниципаль районының «Кощаково авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Кощаково авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Питрәч муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм

аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Кощаково авыл җирлеге Казан шәһәре муниципаль берәмлеге, Богородский, Колай, Шигали авыл җирлекләре һәм Биектау муниципаль районы белән чиктәш.

Кощаково авыл җирлеге чиге Казан шәһәре муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Кощаково авыл җирлеге, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге һәм Биектау муниципаль районы чикләре тоташкан урында Званка авылыннан 3,1 км төньяк-көнбатышта урнашкан 42 нче (44 нче) тоташу ноктасыннан алып Питрәч муниципаль районы чиге буйлап Кощаково, Богородский авыл җирлекләре һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чикләре тоташкан урында Гильдеево авылыннан 2,7 км төньяк-көнбатышта урнашкан 41 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Кощаково авыл җирлеге чиге Богородский авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 41 нче тоташу ноктасыннан алып көнчыгышка таба, Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 450 м урман полосасы буенча, 50 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м «Шәһәр яны урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Столбище участок урманчылыгындагы 102 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буенча, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм төньяк-көнчыгышка таба 300 м, урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буенча 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м бара, 100 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 250 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м, урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 450 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 900 м һәм көньяк-көнчыгышка таба, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 300 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 150 м уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 450 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 100 м урман полосасы буенча, 350 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман полосасы буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасы буенча бара, алга таба, сынык сызык ясап, көнчыгышка таба, Нокса елгасын кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м күмәк бакчалар буйлап уза, сынык сызык ясап, 100 м

төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба «Шәһәр яны урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Столбище участок урманчылыгындагы 5 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш һәм көньяк чикләре буйлап 300 м, күмәк бакчаларның көнчыгыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 700 м һәм 600 м төньяк-көнчыгышка таба, 150 м урман массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, 600 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба 5 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап 150 м көнбатышка таба һәм көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 450 м көньяк-көнбатышка таба бара, көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м, 105 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап 150 м уза, аннары 100 м көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 13 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 250 м төньяк-көнчыгышка таба һәм төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 600 м көньяк-көнчыгышка таба уза, алга таба, сынык сызык ясап, 1,7 км төньяк-көнчыгышка таба 105 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап бара, аннары төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 5 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м уза, алга таба, сынык сызык ясап, 150 м төньяк-көнчыгышка таба 105 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 100 м көньяк-көнчыгышка таба уза, 5 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м уза, 105 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м уза, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 105 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 450 м һәм көньяк-көнчыгыш һәм көньяк чикләре буйлап 350 м көньяк-көнбатышка таба уза, көньяк-көнчыгышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м урман массивы буйлап, 15 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, 15 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 350 м, 102 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м уза, алга таба 450 м урман поло-

сасы буйлап бара, аннары 400 м көньяк-көнбатышка таба урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап дәвам итә, алга таба 18 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 750 м көнчыгышка таба һәм көнчыгыш чиге буйлап 1,0 км көньякка таба уза, 40 м көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 50 м көньяк-көнбатышка таба 108 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап уза, бу урман кварталы буйлап инешкә кадәр 50 м бара, әлеге инеш агымы буенча 1,7 км аска таба Кощаково, Богородский һәм Колай авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Камыш авылыннан 950 м көнчыгышта урнашкан 33 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Кощаково авыл җирлеге чиге Колай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Кощаково, Колай һәм Шигали авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Камыш авылыннан 3,0 км көнчыгышта Шемелка елгасында урнашкан 34 нче тоташу ноктасыннан алып Шемелка елгасы агымы буенча 650 м аска таба елгага инеш койган җиргә кадәр уза, әлеге инеш агымы буенча 1,1 км өскә таба бара, 100 м көньяк-көнбатышка таба буа буенча уза, инеш агымы буенча 1,3 км өскә таба 33 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Кощаково авыл җирлеге чиге Шигали авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 34 нче тоташу ноктасыннан алып Шемелка елгасы агымы буенча 3,0 км өскә таба уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 150 м буаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 1,0 км профильле автомобиль юлы буенча һәм 3,3 км төньяк-көнбатышка таба бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 950 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 150 м төньяк-көнбатышка таба, 900 м төньяк-көнчыгышка таба, 350 м төньяк-көнбатышка таба, 550 м көньяк-көнбатышка таба, 300 м төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 700 м төньяк-көнчыгышка таба, 900 м көнбатышка таба, 800 м төньяк-көнчыгышка таба бара, алга таба 100 м төньяк-көнбатышка таба профильле автомобиль юлы буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 30 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м көньякка таба, 150 м көнбатышка таба, текә ярны кисеп үтеп, 200 м төньякка таба, 350 м төньяк-көнбатышка таба, 40 м урман массивының көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 100 м урман массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м агач-куак массивы буйлап, 51 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буенча 40 м бара, алга таба әлеге аерымланган кишәрлек буйлап 350 м төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 500 м көньякка таба уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м көньяк-

көнчыгышка таба, 100 м көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 250 м көнбатышка таба, 300 м көньяк-көнбатышка таба уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 300 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 400 м урман полосасы буйлап һәм 400 м көнбатышка таба уза, 50 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, төньяк-көнбатышка таба 350 м урман полосасы буйлап, Казан – Шәмәрдән автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, алга таба төньяк-көнчыгышка таба 200 м урман полосасы буйлап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, канауны кисеп үтеп, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м төньякка таба, сынык сызык ясап, 1,6 км төньяк-көнчыгышка таба, 600 м төньяк-көнбатышка таба уза, 100 м урман массивының көньяк чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 600 м төньяк-көнбатышка таба, 250 м төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 500 м көньяк-көнчыгышка таба бара, 100 м урман массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м көньяк-көнчыгышка таба, 50 м төньяк-көнчыгышка таба, 700 м төньяк-көнбатышка таба Кощаково, Шигали авыл җирлекләре һәм Биектау муниципаль районы чикләре тоташкан урында Яңа Шигали авылыннан 2,9 км төньякта урнашкан 38 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Кощаково авыл җирлеге чиге Биектау муниципаль районы белән чиктәш җирдә 42 нче (44 нче) тоташу ноктасыннан алып Питрәч муниципаль районы чиге буйлап 38 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Питрәч муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен
билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
12 нче кушымта

**Питрәч муниципаль районының «Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Питрәч муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге Екатериновка, Кибәч, Татар Казысы, Чыты авыл җирлекләре һәм Балык Бистәсе муниципаль районы белән чиктәш.

Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге чиге Татар Казысы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Керәшен Сәрдәсе, Татар Казысы авыл җирлекләре һәм Балык Бистәсе муниципаль районы чикләре тоташкан урында Татар Казысы авылыннан 4,5 км көньяк-көнбатышта урнашкан 17 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, урман полосасын, чокырны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 5,5 км төньяк-көнчыгышка таба, 1,0 км төньяк-көнбатышка таба уза, аннары 200 м көнбатышка таба чокыр буйлап инешкә кадәр бара, әлеге инеш агымы буенча 300 м аска таба уза, төньяк-көнчыгышка таба, чокырларны кисеп үтеп, 950 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 650 м төньяк-көнчыгышка таба, Питрәч – Чыты – Янсуар автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 950 м төньяк-көнбатышка таба, чокырны, инешне һәм яр буе агач-куак полосасын кисеп үтеп, 400 м төньяк-көнчыгышка таба, 650 м төньякка таба, сынык сызык ясап, 600 м төньяк-көнбатышка таба, 150 м төньяк-көнчыгышка таба Мишә елгасына кадәр бара, әлеге елга буенча 10 м һәм аның агымы буенча 400 м аска таба Керәшен Сәрдәсе, Татар Казысы һәм Кибәч авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Казиле авылыннан 2,0 км

төньяк-көнбатышта Мишә елгасында урнашкан 50 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге чиге Кибәч авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 50 нче тоташу ноктасыннан алып Мишә елгасы агымы буенча 11,6 км аска таба Керәшен Сәрдәсе, Кибәч һәм Чыты авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кибәч авылыннан 2,0 км көньяк-көнбатышта урнашкан 19 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге чиге Чыты авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 19 нчы тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 10 м Мишә елгасы буенча, елганың текә сул ярын, канауны кисеп үтеп, 700 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м төньяк-көнбатышка таба, канауларны ике тапкыр кисеп үтеп, 600 м көньяк-көнбатышка таба, канауларны кисеп үтеп, 200 м агач-куак массивы буйлап, 800 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, чокырны кисеп үтеп, 1,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Питрәч участок урманчылыгындагы 177 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, Питрәч – Чыты – Янсуар һәм Чыты – Керәшен Сәрдәсе автомобиль юлларына бүлеп бирелгән полосаларны кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м агач-куак полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м агач-куак полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары көньякка таба 350 м агач-куак полосасының көнчыгыш чиге буйлап бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м һәм 500 м көньяк-көнчыгышка таба, 900 м көньяк-көнбатышка таба, 1,3 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба 500 м көньяк-көнчыгышка таба 104 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, алга таба, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 104 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м көньяк-көнчыгышка таба, инешне кисеп үтеп, 600 м көньяк-көнбатышка таба уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 106 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м көньяк-көнбатышка таба, 100 м көньяк-көнчыгышка таба, 106 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 700 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 100 м төньяк-көнчыгышка таба, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 450 м көньякка таба Керәшен Сәрдәсе, Чыты

һәм Екатериновка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Иксуар авылыннан 600 м көньяк-көнбатышта урнашкан 18 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге чиге Екатериновка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Керәшен Сәрдәсе, Екатериновка авыл җирлекләре һәм Балык Бистәсе муниципаль районы чикләре тоташкан урында Иксуар авылыннан 800 м көньяк-көнбатышта урнашкан 49 нчы тоташу ноктасыннан алып 150 м төньяк-көнчыгышка таба, Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 18 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге чиге Балык Бистәсе муниципаль районы белән чиктәш җирдә 49 нчы тоташу ноктасыннан алып Питрәч муниципаль районы чиге буйлап 17 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Питрәч муниципаль районы»<br>
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы<br>
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен<br>
билгеләү һәм аларның статусы турында»<br>
Татарстан Республикасы Законына<br>
13 нче кушымта

**Питрәч муниципаль районының «Колай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Колай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Питрәч муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Колай авыл җирлеге Богородский, Кощаково, Питрәч, Шәле, Шигали авыл җирлекләре һәм Лаеш муниципаль районы белән чиктәш.

Колай авыл җирлеге чиге Шәле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Колай, Шәле авыл җирлекләре һәм Лаеш муниципаль районы чикләре тоташкан урында Карповка поселогыннан 2,6 км көньяк-көнбатышта урнашкан 51 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 600 м «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Питрәч участок урманчы-

лыгындагы 129 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м төньякка таба һәм 200 м көньяк-көнчыгышка таба уза, 129 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 450 м бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 129 нчы, 128 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,0 км уза, 128 нче, 127 нче урман кварталлары буйлап 550 м бара, 127 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 300 м төньякка таба, төньяк-көнчыгышка таба 127 нче, 125 нче урман кварталлары һәм, күлне кисеп үтеп, 119 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлеге буйлап, сынык сызык ясап, 1,9 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м уза, төньяк-көнбатышка таба 119 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап 350 м бара, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 119 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, 119 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап «Мәскәү – Уфа» – Карповка автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чигенә кадәр 200 м уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның әлеге чиге буйлап 150 м бара, әлеге автомобиль юлы буйлап 450 м уза, аннары көнчыгышка таба 800 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 181 нче урман кварталының аерымланган кишәрлеге буйлап 250 м бара, әлеге аерымланган кишәрлекнең төньяк чиге буйлап 200 м һәм әлеге аерымланган кишәрлек буйлап 100 м көньякка таба дәвам итә, 250 м төньяк-көнчыгышка таба 181 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 950 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Мишә елгасына кадәр уза, әлеге елга буенча 20 м төньякка таба һәм, Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, аның агымы буенча 13,2 км өскә таба Колай, Шәле һәм Питрәч авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Питрәч авылыннан 1,5 км көньяк-көнбатышта Мишә елгасында урнашкан 28 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Колай авыл җирлеге чиге Питрәч авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 28 нче тоташу ноктасыннан алып Сула елгасы агымы буенча 6,7 км өскә таба, «Мәскәү – Уфа» – Питрәч – Колай автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, аңа кибеп баручы инеш койган җиргә кадәр уза, әлеге инеш агымы буенча 2,9 км өскә таба бара, аннары 900 м төньяк-көнбатышка таба «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Питрәч участок урманчылыгындагы 58 нче

урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап Колай, Питрәч һәм Шигали авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Шихазда авылыннан 3,3 км көньяк-көнбатышта урнашкан 35 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Колай авыл җирлеге чиге Кощаково авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Колай, Кощаково һәм Шигали авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Камыш авылыннан 3,0 км көнчыгышта Шемелка елгасында урнашкан 34 нче тоташу ноктасыннан алып Шемелка елгасы агымы буенча 650 м аска таба елгага инеш койган җиргә кадәр уза, әлеге инеш агымы буенча 1,1 км өскә таба бара, 100 м көньяк-көнбатышка таба буа буенча уза, инеш агымы буенча 1,3 км өскә таба Колай, Кощаково һәм Богородский авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Камыш авылыннан 950 м көнчыгышта урнашкан 33 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Колай авыл җирлеге чиге Шигали авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 35 нче тоташу ноктасыннан алып «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Питрәч участок урманчылыгындагы 58 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м төньяк-көнбатышка таба, төньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 2,8 км көньяк-көнбатышка таба, көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,8 км көньяк-көнчыгышка таба уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 400 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 57 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 550 м бара, алга таба, сынык сызык ясап, 500 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 34 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Колай авыл җирлеге чиге Богородский авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 33 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 100 м чокырның көньяк чиге буйлап, 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 650 м көньяк-көнчыгышка таба, 550 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары 250 м көнбатышка таба урман полосасы буенча бара, урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 200 м көньяк-көнбатышка таба һәм төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 400 м төньяк-көнбатышка таба уза, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 40 м агач-куак полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, алга таба көньяк-көнбатышка авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Питрәч участок урманчылыгындагы 175 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м, «Шәһәр яны урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Столбище участок

муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен
билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
20 нче кушымта

**Питрәч муниципаль районының «Татар Тау Иле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Татар Тау Иле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Питрәч муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Татар Тау Иле авыл җирлеге Белкино, Кибәч, Ленино-Кокушкино, Надеждино, Пановка һәм Пимәр авыл җирлекләре белән чиктәш.

Татар Тау Иле авыл җирлеге чиге Белкино авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Татар Тау Иле, Белкино һәм Пановка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Белкино авылыннан 2,9 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 9 нчы тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары 50 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре

буйлап, 250 м урман полосасы буенча, 850 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап чокырга кадәр уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 100 м чокыр төбе буенча, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешнең чишмә башына кадәр бара, әлеге инеш агымы буенча 1,3 км аска таба уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 2,7 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 100 м төньяк-көнбатышка таба, 50 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 550 м урман полосасы буенча, 300 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 250 м агач-куак полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м агач-куак полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Норма елгасына кадәр бара, әлеге елга агымы буенча 1,3 км өскә таба уза, көнбатышка таба 30 м яр буе агач-куак массивы буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 300 м төньякка таба, 150 м көнбатышка таба бара, аннары 1,0 км урман полосасының көньяк чиге буйлап Татар Тау Иле, Белкино һәм Надеждино авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Надеждино авылыннан 3,4 км көнчыгышта урнашкан 47 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Татар Тау Иле авыл җирлеге чиге Надеждино авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 47 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,6 км көнбатышка таба, 1,2 км көньяк-көнбатышка таба уза, алга таба 50 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,0 км «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Питрәч участок урманчылыгындагы 15 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап Татар Тау Иле, Надеждино һәм Ленино-Кокушкино авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Надеждино авылыннан 1,5 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 44 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Татар Тау Иле авыл җирлеге чиге Ленино-Кокушкино авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Татар Тау Иле, Ленино-Кокушкино һәм Пимәр авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Олы Норма авылыннан 1,4 км төньякта Норма елгасында урнашкан 22 нче тоташу ноктасыннан алып Норма елгасы агымы буенча 1,7 км өскә таба елгага кибеп баручы инеш койган урынга кадәр уза, әлеге инеш агымы буенча 20 м өскә таба бара, аннары, сынык сызык ясап, 400 м төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба төньяк-көнбатышка таба 950 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 200 м авыл

хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 850 м төньякка таба бара, алга таба «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Питрәч участок урманчылыгындагы 17 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 150 м, төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 850 м төньяк-көнбатышка таба һәм төньяк чиге буйлап 150 м көньяк-көнбатышка таба уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м урман полосасының көнбатыш чиге буйлап, 600 м төньякка таба, Казан – Шәмәрдән автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм юл буе урман полосаларын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 16 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 500 м бара, 800 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 44 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Татар Тау Иле авыл җирлеге чиге Пимәр авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Татар Тау Иле, Пимәр һәм Кибәч авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Пановка авылыннан 2,2 км көньяк-көнбатышта урнашкан 21 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 50 м төньяк-көнбатышка таба, 150 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр, аның текә уң ярын кисеп үтеп, әлеге инеш агымы буенча 650 м өскә таба уза, аннары көнбатышка таба 1,3 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Питрәч участок урманчылыгындагы 164 нче урман кварталының аерымланган кишәрлеге буйлап кибеп баручы инешкә кадәр 150 м бара, әлеге инеш агымы буенча 800 м аска таба уза, көньяк-көнбатышка таба, инешнең текә уң ярын кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 165 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 250 м бара, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап «Казан – Шәмәрдән» – Пимәр автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чигенә кадәр уза, автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның әлеге чиге буйлап 1,3 км, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полоса буйлап, аны кисеп үтеп, 100 м уза, төньяк-көнбатышка таба 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м урман утыртмаларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 165 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 300 м бара, 100 м көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көнбатышка таба 165 нче урман кварталының ае-

рымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап 150 м, сынык сызык ясап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 165 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, 165 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап 150 м бара, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 165 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап 250 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м төньяк-көнбатышка таба, 150 м көньякка таба, 250 м төньяк-көнбатышка таба һәм 100 м көньякка таба уза, 1,1 км профильле автомобиль юлы буенча бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 600 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, көнбатышка таба 250 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 700 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Норма елгасына кадәр, елганың текә уң ярын кисеп үтеп, 22 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Татар Тау Иле авыл җирлеге чиге Кибәч авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 21 нче тоташу ноктасыннан алып 150 м көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр уза, әлеге инеш агымы буенча 2,5 км аска таба Татар Тау Иле, Кибәч һәм Пановка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Новоселок авылының көньяк-көнбатыш чигендә урнашкан 8 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Татар Тау Иле авыл җирлеге чиге Пановка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 8 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, 1,9 км төньяк-көнбатышка таба, Казан – Шәмәрдән автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм кибеп баручы инешнең текә ярын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, әлеге инеш агымы буенча 40 м аска таба бара, алга таба, сынык сызык ясап, 100 м төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап башка инешкә кадәр уза, әлеге инеш агымы буенча 100 м өскә таба бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м төньяк-көнбатышка таба һәм 100 м көнчыгышка таба, текә уң ярын кисеп үтеп, инешкә кадәр бара, инеш агымы буенча 3,5 км өскә таба буага кадәр бара, 100 м төньякка таба буа буенча уза, инеш агымы буенча 950 м өскә таба 9 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

«Питрәч муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен
билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
21 нче кушымта

**Питрәч муниципаль районының «Чыты авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Чыты авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Питрәч муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Чыты авыл җирлеге Екатериновка, Кибәч, Күн, Керәшен Сәрдәсе һәм Пимәр авыл җирлекләре белән чиктәш.

Чыты авыл җирлеге чиге Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Чыты, Керәшен Сәрдәсе һәм Кибәч авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кибәч авылыннан 2,0 км көньяк-көнбатышта урнашкан 19 нчы тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 10 м Мишә елгасы буенча, елганың текә сул ярын, канауны кисеп үтеп, 700 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м төньяк-көнбатышка таба, канауларны ике тапкыр кисеп үтеп, 600 м көньяк-көнбатышка таба, канауларны кисеп үтеп, 200 м агач-куак массивы буйлап, 800 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, чокырны кисеп үтеп, 1,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Питрәч участок урманчылыгындагы 177 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, Питрәч – Чыты – Янсуар һәм Чыты – Керәшен Сәрдәсе автомобиль юлларына бүлеп бирелгән полосаларны кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м агач-куак полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м агач-куак полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары көньякка таба 350 м агач-куак полосасының көнчыгыш чиге буйлап бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м һәм 500 м көньяк-көнчыгышка таба, 900 м көньяк-көнбатышка таба, 1,3 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре

буйлап уза, алга таба 500 м көньяк-көнчыгышка таба 104 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, алга таба, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 104 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м көньяк-көнчыгышка таба, инешне кисеп үтеп, 600 м көньяк-көнбатышка таба уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 106 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м көньяк-көнбатышка таба, 100 м көньяк-көнчыгышка таба, 106 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 700 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 100 м төньяк-көнчыгышка таба, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 450 м көньякка таба Чыты, Керәшен Сәрдәсе һәм Екатериновка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Иксуар авылыннан 600 м көньяк-көнбатышта урнашкан 18 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Чыты авыл җирлеге чиге Екатериновка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 18 нче тоташу ноктасыннан алып 400 м төньяк-көнбатышка таба «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Питрәч участок урманчылыгындагы 106 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары 100 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Мәскәү — Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 107 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 500 м көньякка таба, көньяк чиге буйлап 700 м көнбатышка таба һәм көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 200 м төньякка таба, 50 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, алга таба 107 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м бара, 107 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 100 м уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м көньяк-көнбатышка таба, 100 м төньяк-көнбатышка таба бара, 107 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 300 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м, сынык сызык ясап, төньякка таба 107 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 300 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м уза, 107 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Мәскәү — Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнбатыш чигенә кадәр 20 м уза, алга таба 2,7 км төньяк-көнбатышка таба әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полоса чиге буйлап Чыты, Екатериновка һәм Күн авыл җирлекләре чикләре тоташ-

кан урында Екатериновка авылыннан 2,7 км төньякта урнашкан 24 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Чыты авыл җирлеге чиге Күн авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Чыты, Күн һәм Пимәр авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Әлбәдән авылыннан 800 м көньяк-көнчыгышта Мишә елгасында урнашкан 23 нче тоташу ноктасыннан алып Мишә елгасы ермагы агымы буенча 750 м өскә таба уза, аннары, сынык сызык ясап, 550 м көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, әлеге инеш агымы буенча, Питрәч – Чыты – Янсуар автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 4,5 км өскә таба уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 2,6 км көньяк-көнчыгышка таба, 600 м көньяк-көнбатышка таба бара, 100 м урман утыртмаларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м урман утыртмалары буйлап уза, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м агач-куак массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 700 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 24 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Чыты авыл җирлеге чиге Пимәр авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 23 нче тоташу ноктасыннан алып Мишә елгасы агымы буенча 800 м өскә таба уза, аннары көнчыгышка таба 20 м Мишә елгасы буенча, 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 100 м көньяк-көнчыгышка таба агач-куак массивы буйлап кибеп баручы инешкә кадәр уза, әлеге инеш агымы буенча 400 м аска таба аның Мишә елгасына койган җиренә кадәр бара, әлеге елга агымы буенча 7,0 км өскә таба уза, аннары төньякка таба 10 м Мишә елгасы буенча, чокырны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Питрәч участок урманчылыгындагы 68 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,6 км бара, алга таба 700 м төньяк-көнчыгышка таба урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап Чыты, Пимәр һәм Кибәч авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Чыты авылыннан 2,8 км төньякта урнашкан 20 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Чыты авыл җирлеге чиге Кибәч авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 19 нчы тоташу ноктасыннан алып Мишә елгасы агымы буенча 3,4 км аска таба уза, алга таба әлеге елга буенча 10 м төньякка таба, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буй-

лап, 500 м көнчыгышка таба һәм, сынык сызык ясап, 200 м төньяк-көнбатышка таба бара, «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Питрәч участок урманчылыгындагы 177 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 350 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м, 173 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап, чокырларны кисеп үтеп, 200 м уза, 1,4 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, алга таба 850 м көньяк-көнбатышка таба урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 20 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Питрәч муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен
билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
22 нче кушымта

**Питрәч муниципаль районының «Шәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Шәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Питрәч муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Шәле авыл җирлеге Екатериновка, Күн, Колай, Питрәч авыл җирлекләре, Лаеш һәм Балык Бистәсе муниципаль районнары белән чиктәш.

Шәле авыл җирлеге чиге Күн авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Шәле, Күн һәм Екатериновка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Нептун авылыннан 1,6 км төньяк-көнбатышта урнашкан 27 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 40 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м һәм, чокырларны кисеп үтеп, 1,6 км төньяк-көнбатышка таба, 900 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 450 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасының

көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, алга таба төньякка таба, сынык сызык ясап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, төньяк-көнчыгышка таба 150 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, «Мәскәү — Уфа» — Күн автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 400 м «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Питрәч участок урманчылыгындагы 94 нче, 92 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 92 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 50 м бара, әлеге урман кварталы буйлап 400 м көньяк-көнбатышка таба уза, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 92 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап 100 м бара, алга таба, сынык сызык ясап, 550 м көньякка таба 94 нче урман кварталы буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 94 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 800 м бара, әлеге урман кварталы буйлап 400 м һәм аның көнбатыш чиге буйлап 100 м, Мәскәү — Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 93 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м уза, әлеге урман кварталы буенча 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 40 м бара, алга таба төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м, 93 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м уза, Мәскәү — Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кабат кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 93 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буйлап, сынык сызык ясап, 400 м бара, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары төньякка таба 93 нче, 91 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 700 м бара, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 91 нче, 87 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап, канауны кисеп үтеп, 1,8 км уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 85 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 400 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, 79 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,1 км Шәле, Күн һәм Питрәч авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Олан Иле авылыннан 2,1 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 29 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Шәле авыл җирлеге чиге Екатериновка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 27 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, 350 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы

җирләре буйлап, Мәскәү — Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, кибеп баручы инешкә кадәр уза, аннары кибеп баручы инеш агымы буенча 650 м аска таба бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,3 км, «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Питрәч участок урманчылыгындагы 146 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, кибеп баручы инешкә кадәр 350 м уза, әлеге инеш агымы буенча 750 м аска таба бара, аннары көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 200 м, 146 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 450 м бара, алга таба, сынык сызык ясап, 1,3 км көньяк-көнчыгышка таба 146 нчы, 153 нче урман кварталларының көнчыгыш һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап Шәле, Екатериновка авыл җирлекләре һәм Балык Бистәсе муниципаль районы чикләре тоташкан урында Яңа Никольский авылыннан 2,0 км көньякта урнашкан 25 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Шәле авыл җирлеге чиге Балык Бистәсе муниципаль районы белән чиктәш җирдә 25 нче тоташу ноктасыннан алып Питрәч муниципаль районы чиге буйлап Шәле авыл җирлеге, Балык Бистәсе һәм Лаеш муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Яңа Никольский авылыннан 5,1 км көньяк-көнбатышта урнашкан 26 нчы (56 нчы) тоташу ноктасына кадәр уза.

Шәле авыл җирлеге чиге Лаеш муниципаль районы белән чиктәш җирдә 26 нчы (56 нчы) тоташу ноктасыннан алып Питрәч муниципаль районы чиге буйлап Шәле, Колай авыл җирлекләре һәм Лаеш муниципаль районы чикләре тоташкан урында Карповка поселогыннан 2,6 км көньяк-көнбатышта урнашкан 51 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Шәле авыл җирлеге чиге Колай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 51 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 600 м «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Питрәч участок урманчылыгындагы 129 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м төньякка таба һәм 200 м көньяк-көнчыгышка таба уза, 129 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 450 м бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 129 нчы, 128 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,0 км уза, 128 нче, 127 нче урман кварталлары буйлап 550 м бара, 127 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 300 м төньякка таба, төньяк-көнчыгышка таба 127 нче,

125 нче урман кварталлары һәм, күлне кисеп үтеп, 119 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлеге буйлап, сынык сызык ясап, 1,9 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м уза, төньяк-көнбатышка таба 119 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап 350 м бара, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 119 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, 119 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап «Мәскәү — Уфа» — Карповка автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чигенә кадәр 200 м уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның әлеге чиге буйлап 150 м бара, әлеге автомобиль юлы буйлап 450 м уза, аннары көнчыгышка таба 800 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 181 нче урман кварталының аерымланган кишәрлеге буйлап 250 м бара, әлеге аерымланган кишәрлекнең төньяк чиге буйлап 200 м һәм әлеге аерымланган кишәрлек буйлап 100 м көньякка таба дәвам итә, 250 м төньяк-көнчыгышка таба 181 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 950 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Мишә елгасына кадәр уза, әлеге елга буенча 20 м төньякка таба һәм, Мәскәү — Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, аның агымы буенча 13,2 км өскә таба Шәле, Колай һәм Питрәч авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Питрәч авылыннан 1,5 км көньяк-көнбатышта Мишә елгасында урнашкан 28 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Шәле авыл җирлеге чиге Питрәч авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 29 нчы тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Питрәч участок урманчылыгындагы 181 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м, урман массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 750 м көньяк-көнбатышка таба һәм 250 м төньяк-көнбатышка таба, текә сул ярын кисеп үтеп, Мишә елгасына кадәр бара, аннары 10 м Мишә елгасы буенча һәм аның агымы буенча 1,1 км аска таба 28 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Питрәч муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен
билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
23 нче кушымта

**Питрәч муниципаль районының «Шигали авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Шигали авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Питрәч муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Шигали авыл җирлеге Кощаково, Колай, Ленино-Кокушкино, Питрәч авыл җирлекләре һәм Биектау муниципаль районы белән чиктәш.

Шигали авыл җирлеге чиге Биектау муниципаль районы белән чиктәш җирдә Шигали, Ленино-Кокушкино авыл җирлекләре һәм Биектау муниципаль районы чикләре тоташкан урында Иске Шигали авылыннан 3,7 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 37 нче тоташу ноктасыннан алып Питрәч муниципаль районы чиге буйлап Шигали, Кощаково авыл җирлекләре һәм Биектау муниципаль районы чикләре тоташкан урында Яңа Шигали авылыннан 2,9 км төньякта урнашкан 38 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Шигали авыл җирлеге чиге Кощаково авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Шигали, Кощаково һәм Колай авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Камыш авылыннан 3,0 км көнчыгышта Шемелка елгасында урнашкан 34 нче тоташу ноктасыннан алып Шемелка елгасы агымы буенча 3,0 км өскә таба уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 150 м буаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 1,0 км профильле автомобиль юлы буенча һәм 3,3 км төньяк-көнбатышка таба бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 950 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 150 м төньяк-көнбатышка таба, 900 м төньяк-көнчыгышка таба, 350 м төньяк-көнбатышка таба, 550 м көньяк-көнбатышка таба, 300 м төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 700 м төньяк-көнчыгышка таба, 900 м көнбатышка

таба, 800 м төньяк-көнчыгышка таба бара, алга таба 100 м төньяк-көнбатышка таба профильле автомобиль юлы буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 30 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м көньякка таба, 150 м көнбатышка таба, текә ярны кисеп үтеп, 200 м төньякка таба, 350 м төньяк-көнбатышка таба, 40 м урман массивының көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 100 м урман массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м агач-куак массивы буйлап, 51 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буенча 40 м бара, алга таба әлеге аерымланган кишәрлек буйлап 350 м төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 500 м көньякка таба уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м көньяк-көнчыгышка таба, 100 м көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 250 м көнбатышка таба, 300 м көньяк-көнбатышка таба уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 300 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 400 м урман полосасы буйлап һәм 400 м көнбатышка таба уза, 50 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, төньяк-көнбатышка таба 350 м урман полосасы буйлап, Казан – Шәмәрдән автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, алга таба төньяк-көнчыгышка таба 200 м урман полосасы буйлап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, канауны кисеп үтеп, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м төньякка таба, сынык сызык ясап, 1,6 км төньяк-көнчыгышка таба, 600 м төньяк-көнбатышка таба уза, 100 м урман массивының көньяк чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 600 м төньяк-көнбатышка таба, 250 м төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 500 м көньяк-көнчыгышка таба бара, 100 м урман массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м көньяк-көнчыгышка таба, 50 м төньяк-көнчыгышка таба, 700 м төньяк-көнбатышка таба 38 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Шигали авыл җирлеге чиге Колай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Шигали, Колай һәм Питрәч авыл җирлекләре

чикләре тоташкан урында Шихазда авылыннан 3,3 км көньяк-көнбатышта урнашкан 35 нче тоташу ноктасыннан алып «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Питрәч участок урманчылыгындагы 58 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м төньяк-көнбатышка таба, төньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 2,8 км көньяк-көнбатышка таба, көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,8 км көньяк-көнчыгышка таба уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 400 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 57 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 550 м бара, алга таба, сынык сызык ясап, 500 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 34 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Шигали авыл җирлеге чиге Питрәч авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 35 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,2 км төньяк-көнчыгышка таба һәм 1,0 км төньяк-көнбатышка таба уза, «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Питрәч участок урманчылыгындагы 162 нче урман кварталының аерымланган кишәрлеге буйлап 150 м, сынык сызык ясап, 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 55 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 400 м һәм төньяк-көнбатыш чиге буйлап 300 м көньяк-көнбатышка таба бара, төньяк-көнбатышка таба 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 20 м һәм төньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м төньяк-көнчыгышка таба бара, аннары, сынык сызык ясап, 1,5 км төньяк-көнчыгышка таба 53 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 1,7 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м чокырның төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Иске Шигали – Питрәч автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, Сула елгасына кадәр бара, аннары Сула елгасы агымы буенча 350 м аска таба елгага коя торган кибеп баручы инеш тамагына кадәр уза, әлеге инеш агымы буенча 1,5 км өскә таба бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 42 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап 100 м уза, 50 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, алга таба әлеге урман кварталының көньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,1 км төньякка таба, көнчыгыш чиге буйлап 100 м төньяк-көнчыгышка таба бара, 42 нче урман кварталы буйлап 250 м уза, әлеге урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 800 м

һәм төньякка таба 100 м урман кварталы буйлап, 30 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Шигали, Питрәч һәм Ленино-Кокушкино авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кечкенә Пүчинкә поселогыннан 3,1 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 36 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Шигали авыл җирлеге чиге Ленино-Кокушкино авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 36 нчы тоташу ноктасыннан алып Казан – Шәмәрдән автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап 300 м төньяк-көнбатышка таба һәм 600 м көньяк-көнбатышка таба уза, аннары төньяк-көнбатышка таба, юл буе урман полосасын кисеп үтеп, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Питрәч участок урманчылыгындагы 41 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап 100 м бара, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 41 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап 50 м уза, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, алга таба 50 м төньяк-көнчыгышка таба 41 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары 300 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, төньяк-көнчыгышка таба 50 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 41 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап 50 м бара, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба 250 м көнбатышка таба 41 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 1,4 км төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 37 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Питрәч муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен
билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
24 нче кушымта

## Питрәч муниципаль районының «Янсуар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Янсуар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Питрәч муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм

аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Янсуар авыл җирлеге Кибәч, Кавал, Татар Казысы авыл җирлекләре һәм Теләче муниципаль районы белән чиктәш.

Янсуар авыл җирлеге чиге Теләче муниципаль районы белән чиктәш җирдә Янсуар, Татар Казысы авыл җирлекләре һәм Теләче муниципаль районы чикләре тоташкан урында Талкыш авылыннан 4,8 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 12 нче тоташу ноктасыннан алып Питрәч муниципаль районы чиге буйлап Янсуар, Кавал авыл җирлекләре һәм Теләче муниципаль районы чикләре тоташкан урында Кавал авылыннан 1,5 км көнчыгышта урнашкан 11 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Янсуар авыл җирлеге чиге Кавал авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Янсуар, Кавал һәм Кибәч авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Талкыш авылыннан 2,2 км төньяк-көнбатышта урнашкан 15 нче тоташу ноктасыннан алып 950 м төньяк-көнчыгышка таба «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Питрәч участок урманчылыгындагы 30 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көнчыгышка таба 166 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м бара, 166 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап 200 м уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 1,5 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,0 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 31 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 300 м бара, аннары төньякка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 750 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 30 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 11 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Янсуар авыл җирлеге чиге Кибәч авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 15 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 850 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буенча, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Янсуар, Кибәч һәм Татар Казысы авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Талкыш авылыннан 900 м көнбатышта урнашкан 14 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Янсуар авыл җирлеге чиге Татар Казысы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 14 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, 100 м төньяк-көнчыгышка таба «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең

Питрәч участок урманчылыгындагы 34 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 34 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 50 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 34 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 50 м уза, аннары көньякка таба 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 35 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 300 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 400 м көньяк-көнчыгышка таба, 400 м көнчыгышка таба һәм 50 м көньяк-көнбатышка таба, 35 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 250 м бара, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 35 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 600 м уза, алга таба, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 35 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 200 м уза, аннары 200 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, яр буе агач-куак полосасын кисеп үтеп, Мишә елгасына кадәр бара, әлеге елга буенча 10 м уза һәм аның агымы буенча 700 м өскә таба бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 10 м елга буенча һәм 30 м агач-куак массивының көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, чокырны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 1,0 км, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 400 м, урман полосасы буйлап 100 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 300 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м һәм 100 м төньяк-көнчыгышка таба, 450 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, көньяк-көнчыгышка таба, Питрәч – Чыты – Янсуар автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,7 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 12 нче тоташу ноктасына кадәр бара.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 21 ноябре
№ 95-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 1198. «Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 30 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 10-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (I өлеш); 2008, № 10 (II өлеш), 2 – 23 кушымталарны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«Әлки муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен
билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
2 нче кушымта

**«Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Әлки муниципаль районы Ульяновск өлкәсе, Спас, Алексеевск, Нурлат муниципаль районнары белән чиктәш.

«Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге Ульяновск өлкәсе белән чиктәш җирдә Әлки, Нурлат муниципаль

районнары һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Иске Тумба авылыннан 5,4 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 44 нче (1 нче) тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Әлки, Спас муниципаль районнары һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Мулланур Вахитов исемендәге авылдан 8,3 км көньяк-көнбатышта урнашкан 41 нче (2 нче) тоташу ноктасына кадәр бара.

«Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 41 нче (2 нче) тоташу ноктасыннан алып «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Юхмачы участок урманчылыгындагы 140, 131, 123 нче урман кварталларының көнбатыш һәм төньяк чикләре буйлап, сынык сызык ясап, 5,4 км төньяк-көнчыгышка, 8 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка 250 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м, аннары 8 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буенча 50 м кибә торган инешкә кадәр бара, алга таба әлеге инеш агымы буенча аска таба 1,6 км Юхмачы елгасына кадәр бара, шушы елга агымы буенча өскә таба 750 м, 5 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка 20 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 400 м, көньяк-көнбатышка 250 м бара, алга таба, сынык сызык ясап, 110, 121, 120, 119, 118 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап 6,8 км уза, Майна елгасын һәм Барановский инешен кисеп үтеп, 118, 105, 92 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буенча, сынык сызык ясап, 7,0 км төньяк-көнбатышка уза, аннары 92, 80, 73 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буенча төньяк-көнчыгышка 3,0 км бара, 73 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буенча, сынык сызык ясап, 500 м уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 1,7 км, урман массивының төньяк-көнчыгыш чиге буенча 100 м, «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Черная Речка участок урманчылыгындагы 32 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буенча, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка 1,4 км һәм көнбатыш чиге буенча төньяк-көнчыгышка 700 м бара, 30 нчы, 31 нче урман кварталларының көньяк чиге буенча 750 м көньяк-көнбатышка, сынык сызык ясап, 32 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш, көньяк һәм көнбатыш чикләре һәм 31 нче урман кварталының көньяк чиге буенча көнбатышка 2,1 км бара, аннары 31 нче урман кварталының көнбатыш чиге буенча, сы-

нык сызык ясап, төньякка 1,4 км уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка 850 м, урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап төньякка 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 400 м, урман массивының көнбатыш чиге буенча 250 м бара, тагын авыл хуҗалыгы җирләре буенча 400 м, урман массивы буенча кибә торган инешкә кадәр 200 м уза, алга таба әлеге инеш агымы буенча буага кадәр 400 м дәвам итә, аннары буа буйлап төньяк-көнчыгышка 100 м, кибә торган инеш агымы буенча тагын аска таба 4,4 км аның Утка елгасына кушылган җиренә кадәр уза, аннары әлеге елга агымы буенча өскә таба 450 м уза, яр буендагы агач-куаклыклар полосасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 800 м бара, аннары урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап 150 м, Югары Колчурино – Катюшино автомобиль юлын һәм Кузнечиха авылына керү юлын тоташтыра торган автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 450 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көнбатышка 200 м, 14 нче урман кварталының көньяк чиге буенча 1,2 км бара, алга таба 14 нче, 12 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буенча, сынык сызык ясап, төньякка 2,6 км уза, авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 100 м, урман массивы буенча 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка 900 м һәм, сынык сызык ясап, көнбатышка 400 м, сынык сызык ясап, чокыр төбе буенча төньяк-көнбатышка 650 м дәвам итә, кибә торган инеш агымы буенча аска таба 1,6 км, чокыр кырыен кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнчыгышка 100 м бара, урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап 150 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча 500 м, 6 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буенча, сынык сызык ясап, төньякка 1,3 км бара, аннары урман массивы буенча төньяк-көнчыгышка 20 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буенча 100 м, урман полосасының көнчыгыш чиге буенча төньякка 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 1,2 км, урман полосасының көнчыгыш чиге буенча 150 м, 75 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буенча төньяк-көнчыгышка 400 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча, сынык сызык ясап, 350 м дәвам итә, алга таба яңадан әлеге урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буенча 550 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка 1,0 км, урман полосасы буенча 150 м бара, аннары урман полосасының көнбатыш чиге буенча төньяк-көнчыгышка 50 м, урман полосасы буенча 600 м

бара, аннары, «КИМ» – Кузнечиха – Лесная Хмелевка» – Фадеевка һәм Кошки – Чуаш Шәпкәсе автомобиль юлын тоташтыручы профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 550 м уза, урман полосасы буенча 800 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буенча 100 м, Бездна елгасының сулъяк ярындагы кыялы кишәрлекне һәм елганың үзен кисеп үтеп, кибә торган инеш борынына кадәр авыл хуҗалыгы җирләре буенча 600 м бара, аннары әлеге инеш агымы буенча өскә таба 1,8 км уза, авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнчыгышка 700 м һәм төньяк-көнбатышка 25 м бара, алга таба урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буенча 1,3 км, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 700 м төньяк-көнбатышка һәм, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка 2,4 км, Тахтала инешен һәм чокырларны кисеп үтеп, урман утыртмаларының көнчыгыш чиге буенча 400 м бара, сынык сызык ясап, төньякка «Болгар урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Никольский участок урманчылыгындагы 88 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буенча 400 м төньякка уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньякка 250 м һәм көнбатышка 200 м, урман массивы буенча 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м бара, аннары, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка урман утыртмаларының төньяк чиге буенча 1,1 км, 86 нчы, 84 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буенча 2,2 км уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 84 нче, 85 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буенча 1,7 км, авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка, сынык сызык ясап, 750 м уза, аннары урман массивының көнчыгыш чиге буенча 100 м, урман полосасының көньяк чиге буенча төньяк-көнчыгышка 1,3 км, урман массивы буенча төньякка 15 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м, урман массивы буенча 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 150 м, урман массивы буенча 100 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 1,2 км, 75, 76, 77 нче урман кварталларының төньяк чиге буенча, сынык сызык ясап, көнчыгышка 2,7 км уза, аннары, сынык сызык ясап, 78 нче, 74 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буенча төньяк-көнбатышка 1,8 км, 74 нче, 73 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буенча төньяк-көнчыгышка, сынык сызык ясап, 3,5 км бара, алга таба 73 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буенча көньяк-көнчыгышка 750 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 400 м уза, аннары, сынык сызык ясап, 71 нче урман кварталының көнбатыш чиге буенча төньякка 1,8 км, авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнчыгышка

450 м, сынык сызык ясап, 69 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буенча 500 м бара, алга таба, Базарлы Матак – Болгар автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны, кибә торган инешне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча, сынык сызык ясап, 6,0 км уза, аннары урман массивы буенча төньяк-көнбатышка 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 200 м, төньяк-көнчыгышка 1,3 км һәм төньяк-көнбатышка 500 м, 56 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буенча төньяк-көнчыгышка 450 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 3,5 км Әлки, Спас, Алексеевск муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Хлебодаровка авылыннан 3,2 км төньяк-көнбатышта урнашкан 1 нче (31 нче) тоташу ноктасына кадәр бара.

«Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең чиге «Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 1 нче (31 нче) тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 1,6 км, төньяк-көнчыгышка таба 900 м, алга таба урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,9 км уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 800 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, үләт чокырының төньяк чиге буйлап 150 м, «Алексеевск – Югары Колок» – Демидовка – Хлебодаровка автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, яңадан авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,0 км Салман елгасына кадәр уза, аннары, Алексеевск – Югары Колок автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, шушы елга агымы буенча аска таба 1,3 км аның Актай елгасына койган җиренә кадәр уза, Актай елгасы агымы буенча өскә таба 4,6 км бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 900 м уза, 350 м урман полосасы буйлап, 950 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 250 м урман полосасы буйлап, 550 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, көнчыгышка таба 1,1 км урман полосасының көньяк чиге буйлап, көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 1,5 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 750 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 2,3 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Зур Алан участок урманчылыгындагы 77 нче, 78 нче урман кварталларының төньяк һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 1,9 км, сынык сызык ясап, «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт

билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
11 нче кушымта

**Әлки муниципаль районының «Яңа Үргәагар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Яңа Үргәагар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Яңа Үргәагар авыл җирлеге Базарлы Матак, Түбән Әлки, Иске Алпар, Иске Камка, Иске Чаллы һәм Ташбилге авыл җирлекләре белән чиктәш.

Яңа Үргәагар авыл җирлеге чиге Ташбилге авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Яңа Үргәагар, Түбән Әлки һәм Ташбилге авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Татар Суыксуы авылыннан 2,2 км төньяк-көнбатышта урнашкан 22 нче тоташу ноктасыннан алып төньякка таба 150 м, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң төньяк-

көнчыгышка таба 150 м «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Базарлы Матак участок урманчылыгындагы 53 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 450 м 53 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап бара, алга таба, сынык сызык ясап, төньякка таба 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 100 м, сынык сызык ясап, 53 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап һәм 150 м сазлык буйлап Яңа Үргәагар, Ташбилге һәм Базарлы Матак авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Татар Суыксуы авылыннан 2,8 км төньяк-көнбатышта урнашкан 21 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Яңа Үргәагар авыл җирлеге чиге Базарлы Матак авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 21 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 350 м, төньякка таба 400 м бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 50 м «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Базарлы Матак участок урманчылыгындагы 53 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 53 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 750 м 46 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, 1,9 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 950 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 450 м, төньяк-көнчыгышка таба 750 м кибеп баручы инешкә кадәр бара, аның агымы буенча аска таба 300 м икенче кибеп баручы инешкә койган җиренә кадәр уза һәм әлеге инеш агымы буенча аска таба 1,8 км аның Актай Түбәсе елгасына койган җиренә кадәр уза, Базарлы Матак – Мамык автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 3,0 км елга агымы буенча аска таба аның Актай елгасына койган җиренә кадәр уза, 250 м Актай елгасы агымы буенча аска таба Яңа Үргәагар, Базарлы Матак һәм Иске Чаллы авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Базарлы Матак авылыннан 2,4 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 5 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Яңа Үргәагар авыл җирлеге чиге Иске Чаллы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 5 нче тоташу ноктасыннан алып кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба 1,7 км, буа плотинасын кисеп үтә һәм көньяк-көнчыгышка таба 250 м буа буйлап уза, Яңа Үргәагар – Иске Чаллы автомобиль юлына бүлеп бирелгән

полосаны кисеп үтеп, кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба 5,0 км, көньяк-көнчыгышка таба 1,2 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 600 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап Яңа Үргәагар, Иске Чаллы һәм Иске Алпар авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Үргәагар авылыннан 3,2 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 13 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Яңа Үргәагар авыл җирлеге чиге Иске Алпар авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 13 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Базарлы Матак участок урманчылыгындагы 19 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 1,3 км көньякка таба, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, 800 м аның агымы буенча аска таба Маляша инешенә кадәр уза һәм 700 м аның агымы буенча аска таба дәвам итә, аннары көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, 1,6 км әлеге инеш агымы буенча өскә таба уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Базарлы Матак — Мамык автомобиль юлына кадәр бара, аннары 750 м көньяк-көнчыгышка таба әлеге автомобиль юлы буйлап Яңа Үргәагар, Иске Алпар һәм Иске Камка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Үргәагар авылыннан 1,5 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 15 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Яңа Үргәагар авыл җирлеге чиге Иске Камка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 15 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 900 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман массивы буйлап, 350 м урман полосасы буйлап бара, аннары көньякка таба 1,3 км урман полосасының көнбатыш чиге буйлап, 40 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Базарлы Матак участок урманчылыгындагы 49 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 1,1 км һәм көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 300 м бара, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 450 м 48 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Яңа Үргәагар, Иске Камка һәм Түбән Әлки авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Татар Суыксуы авылыннан 2,5 км төньякта урнашкан 20 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Яңа Үргәагар авыл җирлеге чиге Түбән Әлки авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 20 нче тоташу ноктасыннан алып,

сынык сызык ясап, «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Базарлы Матак участок урманчылыгындагы 48, 52, 51, 53 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 3,4 км бара, алга таба, сынык сызык ясап, көнбатышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 100 м сазлык буйлап 22 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Әлки муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен
билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
12 нче кушымта

**Әлки муниципаль районының «Салман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Салман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Салман авыл җирлеге Каргалы, Иске Салман авыл җирлекләре, Алексеевск һәм Спас муниципаль районнары белән чиктәш.

Салман авыл җирлеге чиге Иске Салман авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Салман, Иске Салман авыл җирлекләре һәм Спас муниципаль районы чикләре тоташкан урында Иске Салман авылыннан 2,1 км төньяк-көнбатышта урнашкан 8 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 200 м «Болгар урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Никольский участок урманчылыгындагы 71 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, көнчыгышка таба 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 71 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 50 м уза, алга таба, ике мәртәбә кибеп баручы инешне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 400 м, төньяк-көнбатышка таба 200 м бара, аннары, сынык сызык ясап, 71 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньякка таба 550 м уза, шун-

нан соң көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 350 м 71 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 71 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 250 м 71 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, сынык сызык ясап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 50 м 71 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары көньякка таба 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң көньякка таба 100 м 71 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр бара, инеш агымы буенча аска таба 3,0 км уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 50 м, Салман елгасын һәм «Базарлы Матак – Болгар» – Иске Салман – Иске Такталы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 550 м, көньяк-көнбатышка таба 100 м бара, шуннан соң көньякка таба 350 м җитештерү объектының көнбатыш чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 300 м кибеп баручы инешкә кадәр бара, әлеге инеш агымы буенча өскә таба 3,2 км буага кадәр уза, көньякка таба 50 м буа буйлап бара, алга таба сазлык буйлап көньякка таба 50 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 100 м уза, аннары 700 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң төньякка таба 800 м урман полосасы буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 400 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнчыгышка таба 2,1 км, төньяк-көнчыгышка таба 1,1 км Базарлы Матак – Болгар автомобиль юлына кадәр уза, көньяк-көнчыгышка таба 1,8 км шушы автомобиль юлы буйлап Салман, Иске Салман һәм Каргалы авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Баллыкүл авылыннан 1,0 км төньяк-көнчыгышта Нохрат елгасында урнашкан 7 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Салман авыл җирлеге чиге Спас муниципаль районы белән чиктәш җирдә Салман авыл җирлеге, Спас һәм Алексеевск муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Хлебодаровка авылыннан 3,2 км төньяк-көнбатышка таба урнашкан 1 нче (31 нче) тоташу ноктасыннан алып Әлки муниципаль районы чиге буйлап 8 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Салман авыл җирлеге чиге Алексеевск муниципаль районы белән чиктәш җирдә Салман, Каргалы авыл җирлекләре һәм Алексеевск муниципаль районы чикләре тоташкан урында Демидовка авылыннан 800 м төньяк-көнчыгышта Салман елгасын-

да урнашкан 2 нче тоташу ноктасыннан алып Әлки муниципаль районы чиге буйлап 1 нче (31 нче) тоташу ноктасына кадәр бара.

Салман авыл җирлеге чиге Каргалы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 7 нче тоташу ноктасыннан алып Нохрат елгасы агымы буенча аска таба 2,5 км бара, шуннан соң төньякка таба 250 м буа буйлап бара, буа плотинасын кисеп үтә, 4,6 км яңадан Нохрат елгасы агымы буенча аска таба уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 350 м буа буйлап бара, буа плотинасын кисеп үтә, 3,8 км яңадан Нохрат елгасы агымы буенча аска таба бара, шуннан соң, чокырны кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 1,2 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап профильле автомобиль юлына кадәр уза, 2,5 км әлеге автомобиль юлы буйлап Алексеевск – Югары Колок автомобиль юлына кадәр бара һәм төньяк-көнбатышка таба шушы автомобиль юлы буйлап 3,2 км 2 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Әлки муниципаль районы»<br>муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы<br>муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен<br>билгеләү һәм аларның статусы турында»<br>Татарстан Республикасы Законына<br>13 нче кушымта

## Әлки муниципаль районының «Иске Алпар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Иске Алпар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Иске Алпар авыл җирлеге Яңа Үргәагар, Иске Камка, Иске Чаллы авыл җирлекләре, Алексеевск һәм Нурлат муниципаль районнары белән чиктәш.

Иске Алпар авыл җирлеге чиге Иске Камка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Иске Алпар, Иске Камка һәм Яңа Үргәагар авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Үргәагар авылыннан 1,5 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 15 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 2,4 км Базарлы Матак – Мамык автомобиль юлы буйлап бара, шуннан соң көнчыгышка таба 300 м буа плотинасы буйлап бара, плотинаны кисеп үтә

һәм көньяк-көнчыгышка таба Маляша инеше агымы буенча аска таба 1,1 км икенче буага кадәр бара, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 450 м буа буйлап уза, буаны кисеп үтә һәм 4,0 км яңадан Маляша инеше агымы буенча аска таба әлеге инешнең кибеп баручы кушылдыгына кадәр бара, 1,4 км инеш кушылдыгы агымы буенча аска таба күлгә кадәр уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 100 м күл буйлап бара, алга таба Маляша инеше кушылдыгы агымы буенча аска таба 100 м аның Кече Чирмешән елгасына койган җиренә кадәр бара, 300 м әлеге елга агымы буенча өскә таба бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м сазлыкның көньяк чиге буйлап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м сазлык буйлап уза, аннары, агач-куаклык массивын кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 700 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м агач-куаклык массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, урман полосаларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м һәм төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м бара, 100 м сазлыкның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м сазлыкның көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 950 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң көнчыгышка таба 50 м урман полосасының төньяк чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының төньяк чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман полосасының төньяк чиге буйлап, «Базарлы Матак – Мамык» – Карамалы – Иске Әнҗерә автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Иске Алпар, Иске Камка авыл җирлекләре һәм Нурлат муниципаль районы чикләре тоташкан урында Карамалы авылыннан 1,7 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 17 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Иске Алпар авыл җирлеге чиге Яңа Үргәагар авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Иске Алпар, Яңа Үргәагар һәм Иске Чаллы авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Үргәагар авылыннан 3,2 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 13 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Базарлы Матак участок урманчылыгындагы 19 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 1,3 км көньякка таба, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, 800 м аның агымы буенча аска таба Маляша инешенә кадәр уза һәм 700 м аның агымы буенча аска таба дәвам итә, аннары көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буй-

лап кибеп баручы инешкә кадәр бара, 1,6 км әлеге инеш агымы буенча өскә таба уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Базарлы Матак – Мамык автомобиль юлына кадәр бара, аннары 750 м көньяк-көнчыгышка таба әлеге автомобиль юлы буйлап 15 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Иске Алпар авыл җирлеге чиге Иске Чаллы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 13 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 50 м «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Базарлы Матак участок урманчылыгындагы 19 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап, 900 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң 20 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 350 м, төньяк чиге буйлап көнчыгышка таба 400 м уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Иске Алпар, Иске Чаллы авыл җирлекләре һәм Алексеевск муниципаль районы чикләре тоташкан урында Татар Мулла Иле авылыннан 3,3 км төньяк-көнбатышта урнашкан 14 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Алпар авыл җирлеге чиге Алексеевск муниципаль районы белән чиктәш җирдә 14 нче тоташу ноктасыннан алып Әлки муниципаль районы чиге буйлап Иске Алпар авыл җирлеге, Алексеевск һәм Нурлат муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Иске Алпар авылыннан 4,4 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 16 нчы (30 нчы) тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Алпар авыл җирлеге чиге Нурлат муниципаль районы белән чиктәш җирдә 16 нчы (30 нчы) тоташу ноктасыннан алып Әлки муниципаль районы чиге буйлап 17 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Әлки муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен
билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
14 нче кушымта

## Әлки муниципаль районының «Иске Камка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Иске Камка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм

аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Иске Камка авыл җирлеге Борискино, Түбән Әлки, Яңа Үргәагар, Иске Алпар авыл җирлекләре һәм Нурлат муниципаль районы белән чиктәш.

Иске Камка авыл җирлеге чиге Борискино авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Иске Камка, Борискино авыл җирлекләре һәм Нурлат муниципаль районы чикләре тоташкан урында Карамалы авылыннан 2,2 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 18 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба 2,8 км «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Чуаш Кичүе участок урманчылыгындагы 1 нче, 2 нче урман кварталларының төньяк һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, 900 м шушы инеш агымы буенча аска таба буага кадәр уза, көньяк-көнбатышка таба 150 м буа буйлап плотинага кадәр, төньяк-көнбатышка таба 40 м плотина буйлап, Базарлы Матак – Мамык – Карамалы – Иске Әнҗерә автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 100 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 2,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м сазлыкның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 750 м, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 1,0 км, төньяк-көнбатышка таба 650 м уза, аннары 550 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 550 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр уза, 1,1 км инеш агымы буенча аска таба аның Кече Чирмешән елгасына койган җиренә кадәр бара, 3,4 км шушы елга агымы буенча аска таба Иске Камка, Борискино һәм Түбән Әлки авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Рус Суыксуы авылыннан 250 м көньяк-көнчыгышта Кече Чирмешән елгасында урнашкан 19 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Камка авыл җирлеге чиге Түбән Әлки авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 19 нчы тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба 10 м Кече Чирмешән елгасы буйлап аның сулъяк ярына кадәр уза, шушы елганың текә ярын кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м агач-куаклык полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, чокырны һәм ки-

беп баручы инешне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 2,6 км һәм төньяк-көнчыгышка таба 2,7 км, 300 м урман полосасы буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, урман полосасын һәм күлне кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 1,4 км, 100 м «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Базарлы Матак участок урманчылыгындагы 55 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап бара, сынык сызык ясап, 1,7 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Иске Камка, Түбән Әлки һәм Яңа Үргәагар авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Татар Суыксуы авылыннан 2,5 км төньякта урнашкан 20 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Камка авыл җирлеге чиге Яңа Үргәагар авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 15 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 900 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман массивы буйлап, 350 м урман полосасы буйлап бара, аннары көньякка таба 1,3 км урман полосасының көнбатыш чиге буйлап, 40 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Базарлы Матак участок урманчылыгындагы 49 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 1,1 км һәм көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 300 м бара, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 450 м 48 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 20 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Иске Камка авыл җирлеге чиге Иске Алпар авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 15 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 2,4 км Базарлы Матак – Мамык автомобиль юлы буйлап бара, шуннан соң көнчыгышка таба 300 м буа плотинасы буйлап бара, плотинаны кисеп үтә һәм көньяк-көнчыгышка таба Маляша инеше агымы буенча аска таба 1,1 км икенче буага кадәр бара, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 450 м буа буйлап уза, буаны кисеп үтә һәм 4,0 км яңадан Маляша инеше агымы буенча аска таба әлеге инешнең кибеп баручы кушылдыгына кадәр бара, 1,4 км инеш кушылдыгы агымы буенча аска таба күлгә кадәр уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 100 м күл буйлап бара, алга таба Маляша инеше кушылдыгы агымы буенча аска таба 100 м аның Кече Чирмешән елгасына койган җиренә кадәр бара, 300 м әлеге елга агымы буенча өскә таба бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м сазлыкның көньяк чиге буйлап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м сазлык буйлап уза, аннары, агач-куаклык массивын кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 700 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м

агач-куаклык массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, урман полосаларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м һәм төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м бара, 100 м сазлыкның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м сазлыкның көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 950 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң көнчыгышка таба 50 м урман полосасының төньяк чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының төньяк чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман полосасының төньяк чиге буйлап, «Базарлы Матак – Мамык» – Карамалы – Иске Әнҗерә автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Иске Камка, Иске Алпар авыл җирлекләре һәм Нурлат муниципаль районы чикләре тоташкан урында Карамалы авылыннан 1,7 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 17 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Иске Камка авыл җирлеге чиге Нурлат муниципаль районы белән чиктәш җирдә 17 нче тоташу ноктасыннан алып Әлки муниципаль районы чиге буйлап 18 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Әлки муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен
билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
15 нче кушымта

## Әлки муниципаль районының «Иске Матак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Иске Матак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Иске Матак авыл җирлеге Базарлы Матак, Югары Колчурино, Кошки, Иске Салман, Иске Карата һәм Ташбилге авыл җирлекләре белән чиктәш.

Иске Матак авыл җирлеге чиге Иске Салман авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Иске Матак, Иске Салман һәм Базарлы Матак авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Базарлы Матак авылыннан 650 м көньяк-көнбатышта урнашкан 11 нче тоташу ноктасыннан алып Актай елгасы агымы буенча өскә таба 1,2 км бара, шуннан соң «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Базарлы Матак участок урманчылыгындагы 17 нче урман кварталының көньяк чиге буенча көнбатышка таба 50 м уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнбатышка таба 100 м, төньяк-көнчыгышка таба 50 м бара, аннары 17 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 700 м уза, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 600 м 16 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 3,5 км урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м урман полосасы буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, алга таба 6 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 950 м, төньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 350 м уза, аннары 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м 7 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 400 м 7 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнбатышка таба 350 м, көньяк-көнбатышка таба 350 м бара, аннары 5 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 450 м уза, шуннан соң көнбатышка таба 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 5 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап Салман кибеп баручы инешенә кадәр бара, аның агымы буенча өскә таба 450 м бара, аннары, урман массивын кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 1,5 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, «Болгар урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Никольский участок урманчылыгындагы 98 нче урман кварталының төньяк һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап 500 м уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнбатышка таба 450 м, көньяк-көнбатышка таба 800 м бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 100 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 2,1 км уза, сынык сызык ясап, 1,5 км 100 нче, 102 нче урман кварталлары буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 150 м 102 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 750 м 102 нче,

101 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 104 нче, 105 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка таба 850 м Кызыл Чишмә инешенә кадәр бара, әлеге инеш агымы буенча аска таба 3,6 км Иске Матак, Иске Салман һәм Кошки авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Татар Төгәлбәе авылыннан 2,9 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 10 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Матак авыл җирлеге чиге Базарлы Матак авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 11 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 950 м Актай елгасының уңъяк яры буйлап бара, аннары көньякка таба 700 м Актай елгасына койган Черная Речка инешенең сулъяк яры буйлап уза, алга таба әлеге инеш агымы буенча өскә таба 1,3 км Иске Матак, Ташбилге һәм Базарлы Матак авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Базарлы Матак авылыннан 1,3 км көньяк-көнбатышта урнашкан 12 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Иске Матак авыл җирлеге чиге Ташбилге авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Иске Матак, Ташбилге һәм Иске Карата авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Сиктерме поселогыннан 1,5 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 24 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 50 м урман массивының көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 450 м һәм төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 2,8 км Базарлы Матак – Чуаш Шәпкәсе автомобиль юлына кадәр бара, төньяк-көнчыгышка таба 3,5 км шушы автомобиль юлы буйлап Черная Речка инешенә кадәр уза һәм аның агымы буенча аска таба 1,8 км 12 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Иске Матак авыл җирлеге чиге Иске Карата авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Иске Матак, Иске Карата һәм Югары Колчурино авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Сиктерме поселогыннан 2,3 км көньяк-көнбатышта урнашкан 25 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 30 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м сазлык буйлап бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 450 м, көнчыгышка таба 1,4 км, Шәпкә елгасын кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 700 м бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 200 м «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт

бюджет учреждениесенең Базарлы Матак участок урманчылыгындагы 65 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 500 м 65 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м бара, аннары 60 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 200 м уза, шуннан соң көнбатышка таба, сынык сызык ясап, инешне кисеп үтеп, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, инешне кисеп үтеп, 2,8 км 60 нчы урман кварталының көнбатыш, төньяк-көнбатыш һәм төньяк чикләре буйлап уза, 850 м 61 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 24 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Иске Матак авыл җирлеге чиге Югары Колчурино авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Иске Матак, Югары Колчурино һәм Кошки авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Татар Төгәлбәе авылыннан 3,7 км көнчыгышта урнашкан 26 нчы тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Базарлы Матак участок урманчылыгындагы 67 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 2,2 км, төньяк чиге буйлап көнчыгышка таба 600 м, көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 1,6 км уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 650 м 70 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң көнчыгышка таба 150 м 103 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап бара, 200 м урман полосасы буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 850 м урман полосасының төньяк чиге буйлап, 30 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 750 м 76 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 3,6 км 76, 77, 78 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап 25 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Матак авыл җирлеге чиге Кошки авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 10 нчы тоташу ноктасыннан алып Салкын Чишмә инеше агымы буенча өскә таба 2,9 км бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 150 м, көньяк-көнчыгышка таба 2,0 км, берничә мәртәбә текә ярларны, урман массивларын һәм Кошки – Чуаш Шәпкәсе автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 200 м «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Базарлы Матак участок урманчылыгындагы 102 нче урман

кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап 26 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

«Әлки муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен
билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
16 нчы кушымта

**Әлки муниципаль районының «Иске Салман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Иске Салман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Иске Салман авыл җирлеге Базарлы Матак, Каргалы, Кошки, Салман, Иске Матак авыл җирлекләре һәм Спас муниципаль районы белән чиктәш.

Иске Салман авыл җирлеге чиге Салман авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Иске Салман, Салман авыл җирлекләре һәм Спас муниципаль районы чикләре тоташкан урында Иске Салман авылыннан 2,1 км төньяк-көнбатышта урнашкан 8 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 200 м «Болгар урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Никольский участок урманчылыгындагы 71 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, көнчыгышка таба 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 71 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 50 м уза, алга таба, ике мәртәбә кибеп баручы инешне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 400 м, төньяк-көнбатышка таба 200 м бара, аннары, сынык сызык ясап, 71 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньякка таба 550 м уза, шуннан соң көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 350 м 71 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 71 нче ур-

ман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 250 м 71 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, сынык сызык ясап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 50 м 71 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары көньякка таба 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң көньякка таба 100 м 71 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр бара, инеш агымы буенча аска таба 3,0 км уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 50 м, Салман елгасын һәм «Базарлы Матак – Болгар» – Иске Салман – Иске Такталы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 550 м, көньяк-көнбатышка таба 100 м бара, шуннан соң көньякка таба 350 м җитештерү объектының көнбатыш чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 300 м кибеп баручы инешкә кадәр бара, әлеге инеш агымы буенча өскә таба 3,2 км буага кадәр уза, көньякка таба 50 м буа буйлап бара, алга таба сазлык буйлап көньякка таба 50 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 100 м уза, аннары 700 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң төньякка таба 800 м урман полосасы буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 400 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнчыгышка таба 2,1 км, төньяк-көнчыгышка таба 1,1 км Базарлы Матак – Болгар автомобиль юлына кадәр уза, көньяк-көнчыгышка таба 1,8 км шушы автомобиль юлы буйлап Иске Салман, Салман һәм Каргалы авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Баллыкүл авылыннан 1,0 км төньяк-көнчыгышта Нохрат елгасында урнашкан 7 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Салман авыл җирлеге чиге Каргалы авыл җирлеге чиктәш җирдә Иске Салман, Каргалы һәм Салман авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Баллыкүл авылыннан 1,7 км көнчыгышка таба Нохрат елгасында урнашкан 6 нчы тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба Базарлы Матак – Болгар автомобиль юлы буйлап 7 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Салман авыл җирлеге чиге Базарлы Матак авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 6 нчы тоташу ноктасыннан алып көньякка таба, сынык сызык ясап, урман массивын кисеп үтеп, 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Базарлы Матак участок урманчылыгындагы 13 нче урман

кварталының көнчыгыш чиге буйлап 350 м бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 1,2 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм, сынык сызык ясап, 4,7 км 14, 15, 16, 17 нче урман кварталларының төньяк, төньяк-көнчыгыш, көнчыгыш, көньяк-көнчыгыш һәм көньяк чикләре буйлап, сынык сызык ясап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Иске Салман, Базарлы Матак һәм Иске Матак авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Базарлы Матак авылыннан 650 м көньяк-көнбатышта урнашкан 11 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Иске Салман авыл җирлеге чиге Иске Матак авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 11 нче тоташу ноктасыннан алып Актай елгасы агымы буенча өскә таба 1,2 км бара, шуннан соң «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Базарлы Матак участок урманчылыгындагы 17 нче урман кварталының көньяк чиге буенча көнбатышка таба 50 м уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнбатышка таба 100 м, төньяк-көнчыгышка таба 50 м бара, аннары 17 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 700 м уза, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 600 м 16 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 3,5 км урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м урман полосасы буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, алга таба 6 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 950 м, төньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 350 м уза, аннары 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м 7 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 400 м 7 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнбатышка таба 350 м, көньяк-көнбатышка таба 350 м бара, аннары 5 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 450 м уза, шуннан соң көнбатышка таба 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 5 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап Салман кибеп баручы инешенә кадәр бара, аның агымы буенча өскә таба 450 м бара, аннары, урман массивын кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 1,5 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, «Болгар урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Никольский участок урманчылыгындагы 98 нче урман кварталының төньяк һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап 500 м уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнбатышка таба 450 м, көньяк-көнбатышка

таба 800 м бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 100 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 2,1 км уза, сынык сызык ясап, 1,5 км 100 нче, 102 нче урман кварталлары буйлап бара, алга таба көньяк-көнбатышка таба 150 м 102 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 750 м 102 нче, 101 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 104 нче, 105 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка таба 850 м Кызыл Чишмә инешенә кадәр бара, әлеге инеш агымы буенча аска таба 3,6 км Иске Салман, Иске Матак һәм Кошки авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Татар Төгәлбәе авылыннан 2,9 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 10 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Салман авыл җирлеге чиге Кошки авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 10 нчы тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба 250 м буа буйлап бара, буа плотинасын кисеп үтә, алга таба Кызыл Чишмә инеше агымы буенча аска таба 1,9 км шушы инешкә кибеп баручы инеш койган җиргә кадәр уза, кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба 1,5 км бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 100 м урман утыртмалары буйлап, 1,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң көнбатышка таба 1,1 км «Болгар урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Никольский участок урманчылыгындагы 99 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман массивы буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 1,3 км урман полосасының көньяк һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м һәм көньяк-көнбатышка таба 200 м Иске Салман, Кошки авыл җирлекләре һәм Спас муниципаль районы чикләре тоташкан урында Кошки авылыннан 3,1 км төньякта урнашкан 9 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Иске Салман авыл җирлеге чиге Спас муниципаль районы белән чиктәш җирдә 9 нчы тоташу ноктасыннан алып Әлки муниципаль районы чиге буйлап 8 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Әлки муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен
билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
17 нче кушымта

**Әлки муниципаль районының «Иске Карата авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Иске Карата авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Иске Карата авыл җирлеге Югары Колчурино, Түбән Әлки, Иске Матак, Ташбилге, Чуаш Кичүе һәм Чуаш Борнае авыл җирлекләре белән чиктәш.

Иске Карата авыл җирлеге чиге Югары Колчурино авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Иске Карата, Югары Колчурино һәм Чуаш Борнае авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Түбән Колчурино авылыннан 700 м көнчыгышта урнашкан 30 нчы тоташу ноктасыннан алып, Инча елгасын кисеп үтеп, төньякка таба 700 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 550 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман массивы буйлап, Бовар елгасын кисеп үтеп, 350 м «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Базарлы Матак участок урманчылыгындагы 79 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, 2,1 км 78 нче урман кварталының көнчыгыш һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап Иске Карата, Югары Колчурино һәм Иске Матак авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Сиктерме поселогыннан 2,3 км көньяк-көнбатышта урнашкан 25 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Карата авыл җирлеге чиге Иске Матак авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 25 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 30 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м сазлык буйлап бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-

көнчыгышка таба 450 м, көнчыгышка таба 1,4 км, Шәпкә елгасын кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 700 м бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 200 м «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Базарлы Матак участок урманчылыгындагы 65 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 500 м 65 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м бара, аннары 60 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 200 м уза, шуннан соң көнбатышка таба, сынык сызык ясап, инешне кисеп үтеп, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, инешне кисеп үтеп, 2,8 км 60 нчы урман кварталының көнбатыш, төньяк-көнбатыш һәм төньяк чикләре буйлап уза, 850 м 61 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап Иске Карата, Иске Матак һәм Ташбилге авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Сиктерме поселогыннан 1,5 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 24 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Иске Карата авыл җирлеге чиге Ташбилге авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 24 нче тоташу ноктасыннан алып 2,0 км көньяк-көнчыгышка таба «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Базарлы Матак участок урманчылыгындагы 61 нче, 62 нче урман кварталларының төньяк һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап бара, аннары 63 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап көнчыгышка таба 1,7 км уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 64 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш һәм төньяк чикләре буйлап 1,7 км бара, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,0 км уза, аннары көнчыгышка таба 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Иске Карата, Ташбилге һәм Түбән Әлки авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Урта Әлки авылыннан 2,9 км төньяк-көнбатышта урнашкан 23 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Карата авыл җирлеге чиге Түбән Әлки авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 23 нче тоташу ноктасыннан алып көньякка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 100 м «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Базарлы Матак участок урманчылыгындагы 108 нче урман кварталының аерымланган кишәрлеге буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 350 м урман утыртмаларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м сазлыкның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан

соң көньякка таба 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман массивының көнчыгыш чиге буйлап, 300 м 108 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 200 м урман массивының көнбатыш чиге буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, әлеге инеш агымы буенча аска таба ул башка инешкә койганчы 1,6 км уза һәм әлеге инеш агымы буенча аска таба 1,3 км бара, шуннан соң көньякка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман полосасының көнбатыш чиге буйлап, 600 м урман полосасы буйлап, Ата елгасын һәм Түбән Әлки – Чуаш Борнае – Югары Колчурино автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 700 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 1,3 км урман полосасының көнбатыш чиге буйлап, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Иске Карата, Түбән Әлки һәм Чуаш Кичүе авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Иске Карата авылыннан 1,9 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 32 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Карата авыл җирлеге чиге Чуаш Кичүе авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 32 нче тоташу ноктасыннан алып кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба 800 м уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,4 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап Иске Карата, Чуаш Кичүе һәм Чуаш Борнае авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Иске Карата авылыннан 3,1 км көньякта урнашкан 31 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Иске Карата авыл җирлеге чиге Чуаш Борнае авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 31 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 1,9 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Түбән Әлки – Чуаш Борнае – Югары Колчурино автомобиль юлына кадәр уза, көньяк-көнбатышка таба 50 м шушы автомобиль юлы буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Борнай елгасына кадәр бара, шушы елга агымы буенча аска таба 1,0 км уза, шуннан соң Инча елгасы агымы буенча өскә таба 2,0 км бара, аннары, Сиктерме-Хузангай авылына килүче автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 1,5 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң көнбатышка таба 1,1 км урман полосасының көньяк чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 30 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

«Әлки муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен
билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
18 нче кушымта

**Әлки муниципаль районының «Иске Чаллы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Иске Чаллы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Иске Чаллы авыл җирлеге Базарлы Матак, Каргалы, Яңа Үргәагар, Иске Алпар авыл җирлекләре һәм Алексеевск муниципаль районы белән чиктәш.

Иске Чаллы авыл җирлеге чиге Каргалы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Иске Чаллы, Каргалы авыл җирлекләре һәм Алексеевск муниципаль районы чикләре тоташкан урында Бибай Чаллысы авылыннан 2,6 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 3 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 750 м «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Зур Алан участок урманчылыгындагы 77 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр бара, 5,2 км әлеге инеш агымы буенча аска таба аның Чаллы елгасына койган җиренә кадәр бара, 1,6 км шушы елга агымы буенча аска таба аның Актай елгасына койган җиренә кадәр уза, 650 м Актай елгасы агымы буенча өскә таба Иске Чаллы, Каргалы һәм Базарлы Матак авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Каргалы авылыннан 2,8 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 4 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Иске Чаллы авыл җирлеге чиге Алексеевск муниципаль районы белән чиктәш җирдә Иске Чаллы, Иске Алпар авыл җирлекләре һәм Алексеевск муниципаль районы чикләре тоташкан урында Татар Мулла Иле авылыннан 3,3 км төньяк-көнбатышта урнашкан 14 нче тоташу ноктасыннан алып Әлки муниципаль районы чиге буйлап 3 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Чаллы авыл җирлеге чиге Иске Алпар авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Иске Чаллы, Иске Алпар һәм Яңа Үргәагар авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Үргәагар авылыннан 3,2 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 13 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 50 м «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Базарлы Матак участок урманчылыгындагы 19 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап, 900 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң 20 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 350 м, төньяк чиге буйлап көнчыгышка таба 400 м уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 14 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Чаллы авыл җирлеге чиге Яңа Үргәагар авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Иске Чаллы, Яңа Үргәагар һәм Базарлы Матак авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Базарлы Матак авылыннан 2,4 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 5 нче тоташу ноктасыннан алып кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба 1,7 км, буа плотинасын кисеп үтә һәм көньяк-көнчыгышка таба 250 м буа буйлап уза, Яңа Үргәагар – Иске Чаллы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба 5,0 км, көньяк-көнчыгышка таба 1,2 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 600 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 13 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Иске Чаллы авыл җирлеге чиге Базарлы Матак авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 4 нче тоташу ноктасыннан алып Актай елгасы агымы буенча өскә таба 5,8 км 5 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Әлки муниципаль районы»<br>муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы<br>муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен<br>билгеләү һәм аларның статусы турында»<br>Татарстан Республикасы Законына<br>19 нчы кушымта

**Әлки муниципаль районының «Ташбилге авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Ташбилге авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын

(«Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Ташбилге авыл җирлеге Базарлы Матак, Түбән Әлки, Яңа Үргәагар, Иске Матак һәм Иске Карата авыл җирлекләре белән чиктәш.

Ташбилге авыл җирлеге чиге Иске Матак авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Ташбилге, Иске Матак һәм Иске Карата авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Сиктерме поселогыннан 1,5 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 24 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 50 м урман массивының көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 450 м һәм төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 2,8 км Базарлы Матак – Чуаш Шәпкәсе автомобиль юлына кадәр бара, төньяк-көнчыгышка таба 3,5 км шушы автомобиль юлы буйлап Черная Речка инешенә кадәр уза һәм аның агымы буенча аска таба 1,8 км Ташбилге, Иске Матак һәм Базарлы Матак авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Базарлы Матак авылыннан 1,3 км көньяк-көнбатышта урнашкан 12 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Ташбилге авыл җирлеге чиге Базарлы Матак авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 12 нче тоташу ноктасыннан алып көнчыгышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Базарлы Матак участок урманчылыгындагы 96 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап, Базарлы Матак – Татар Шәпкәсе автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны, урман полосасын һәм аэродромның очып китү полосасын кисеп үтеп, 2,7 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, алга таба, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба, Актай Түбәсе елгасын кисеп үтеп, 2,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 800 м 43 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, 45 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 200 м бара, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба, сынык сызык ясап, 45 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 750 м һәм көньяк чиге буйлап көнчыгышка таба 1,1 км уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 200 м 96 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара,

1,3 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Ташбилге, Базарлы Матак һәм Яңа Үргәагар авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Татар Суыксуы авылыннан 2,8 км төньяк-көнбатышта урнашкан 21 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Ташбилге авыл җирлеге чиге Яңа Үргәагар авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Ташбилге, Яңа Үргәагар һәм Түбән Әлки авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Татар Суыксуы авылыннан 2,2 км төньяк-көнбатышта урнашкан 22 нче тоташу ноктасыннан алып төньякка таба 150 м, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 150 м «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Базарлы Матак участок урманчылыгындагы 53 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 450 м 53 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап бара, алга таба, сынык сызык ясап, төньякка таба 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 100 м, сынык сызык ясап, 53 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап һәм 150 м сазлык буйлап 21 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Ташбилге авыл җирлеге чиге Түбән Әлки авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Түбән Әлки, Яңа Үргәагар һәм Ташбилге авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Татар Суыксуы авылыннан 2,2 км төньяк-көнбатышта урнашкан 22 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 950 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, Алексеевск – Югары Колок автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 40 м бара, 1,3 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Ташбилге, Түбән Әлки һәм Иске Карата авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Урта Әлки авылыннан 2,9 км төньяк-көнбатышта урнашкан 23 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Ташбилге авыл җирлеге чиге Иске Карата авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 24 нче тоташу ноктасыннан алып 2,0 км көньяк-көнчыгышка таба «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Базарлы Матак участок урманчылыгындагы 61 нче, 62 нче урман кварталларының төньяк һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап бара, аннары 63 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап көнчыгышка таба 1,7 км уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 64 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш һәм төньяк чикләре буйлап 1,7 км бара, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,0 км уза, аннары көнчыгышка таба 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 23 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Әлки муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен
билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
20 нче кушымта

**Әлки муниципаль районының «Чуаш Кичүе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Чуаш Кичүе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Чуаш Кичүе авыл җирлеге Борискино, Түбән Әлки, Түбән Кәчи, Иске Карата, Чуаш Борнае, Юхмачы авыл җирлекләре һәм Нурлат муниципаль районы белән чиктәш.

Чуаш Кичүе авыл җирлеге чиге Юхмачы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Чуаш Кичүе, Юхмачы авыл җирлекләре һәм Нурлат муниципаль районы чикләре тоташкан урында Юхмачы авылыннан 1,6 км көнчыгышта урнашкан 35 нче тоташу ноктасыннан алып 150 м Кече Чирмешән елгасы агымы буенча өскә таба бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 100 м сазлык буйлап уза, шуннан соң төньякка таба 1,3 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м сазлык буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м сазлык буйлап Чуаш Кичүе, Юхмачы һәм Түбән Кәчи авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Юхмачы авылыннан 2,4 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 36 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Чуаш Кичүе авыл җирлеге чиге Түбән Кәчи авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 36 нчы тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 50 м сазлык буйлап, канауны кисеп үтеп, 850 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м сазлык буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 450 м сазлык буйлап, 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м сазлыкның көнбатыш чиге буйлап уза, аннары төньякка таба 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м сазлыкның көнбатыш чиге буйлап, Чия елгасын кисеп үтеп, 700 м сазлык буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 850 м авыл хуҗалыгы җирләре

буйлап, 50 м сазлык буйлап, агач-куаклык полосасын һәм Алексеевск – Югары Колок автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,0 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары көнбатышка таба 150 м урман полосасының көньяк чиге буйлап һәм 100 м төньяк чиге буйлап бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м һәм 100 м көньяк-көнбатышка таба уза, аннары 1,0 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 300 м урман полосасы буйлап, 750 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, алга таба «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Черная Речка участок урманчылыгындагы 50 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка таба 150 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 200 м һәм көньяк-көнбатышка таба 200 м бара, алга таба 50 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш һәм көньяк чикләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 300 м уза, аннары көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Чия елгасына кадәр бара, аның агымы буенча өскә таба 800 м плотинага кадәр уза, төньяк-көнчыгышка таба 50 м плотина буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 700 м буаның сулъяк яры буйлап, Чия елгасы агымы буенча өскә таба 2,6 км шушы елгага кибеп баручы инеш койган җиргә кадәр бара, 150 м әлеге инеш агымы буенча өскә таба уза, аннары көнбатышка таба, чокырны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Чуаш Кичүе, Түбән Кәчи һәм Чуаш Борнае авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Йолдыз поселогыннан 600 м көньяк-көнбатышта урнашкан 38 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Чуаш Кичүе авыл җирлеге чиге Чуаш Борнае авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 38 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба 1,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 3,8 км, сынык сызык ясап, «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Черная Речка участок урманчылыгындагы 42, 39, 40 нчы урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 2,2 км 40 нчы, 39 нчы урман кварталларының төньяк һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 38 нче урман кварталының көнчыгыш һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап 950 м уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 800 м урман полосасының көньяк-

көнчыгыш чиге буйлап Чуаш Кичүе, Чуаш Борнае һәм Иске Карата авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Иске Карата авылыннан 3,1 км көньякта урнашкан 31 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Чуаш Кичүе авыл җирлеге чиге Иске Карата авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Чуаш Кичүе, Иске Карата һәм Түбән Әлки авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Иске Карата авылыннан 1,9 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 32 нче тоташу ноктасыннан алып кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба 800 м уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,4 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 31 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Чуаш Кичүе авыл җирлеге чиге Түбән Әлки авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 32 нче тоташу ноктасыннан алып кибеп баручы инеш агымы буйлап аска таба 450 м бара, аннары көнчыгышка таба 50 м чокыр буйлап, урман полосасын кисеп үтеп, 1,9 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,2 км урман полосасының көньяк чиге буйлап, 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Алексеевск – Югары Колок автомобиль юлына кадәр бара, көньяк-көнчыгышка таба 450 м шушы автомобиль юлы буйлап Түбән Әлки авылына керә торган автомобиль юлы белән кисешкәнче уза, төньяк-көнчыгышка таба 450 м шушы автомобиль юлы буйлап бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнчыгышка таба 2,7 км, 50 м үләт чокырының көньяк чиге буйлап, сазлыкны кисеп үтеп, 800 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м көньяк-көнчыгышка таба Кече Чирмешән елгасына кадәр, шушы елга агымы буенча 15 м Чуаш Кичүе, Түбән Әлки һәм Борискино авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Садык авылыннан 250 м көнбатышта урнашкан 33 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Чуаш Кичүе авыл җирлеге чиге Борискино авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 33 нче тоташу ноктасыннан алып Кече Чирмешән елгасы агымы буенча аска таба 3,8 км бара, аннары, урман массивын кисеп үтеп, көнчыгышка таба 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Чуаш Кичүе участок урманчылыгындагы 13 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап уза, шуннан соң, Чуаш Кичүе – Иске Әнҗерә – Борискино автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньякка таба 300 м 7 нче, 14 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м 14 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 14 нче урман кварталы буйлап

бара, аннары көнчыгышка таба 4,8 км 14, 15, 16, 17 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап уза, шуннан соң көньякка таба 4,8 км 18, 25, 36, 41 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап Чуаш Кичүе, Борискино авыл җирлекләре һәм Нурлат муниципаль районы чикләре тоташкан урында Яңа Әнҗерә авылыннан 3,2 км көньяк-көнбатышта урнашкан 34 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Чуаш Кичүе авыл җирлеге чиге Нурлат муниципаль районы белән чиктәш җирдә 34 нче тоташу ноктасыннан алып Әлки муниципаль районы чиге буйлап 35 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Әлки муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен
билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
21 нче кушымта

## Әлки муниципаль районының «Чуаш Борнае авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Чуаш Борнае авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Чуаш Борнае авыл җирлеге Югары Колчурино, Түбән Кәчи, Иске Карата, Чуаш Кичүе, Чиябаш авыл җирлекләре һәм Спас муниципаль районы белән чиктәш.

Чуаш Борнае авыл җирлеге чиге Югары Колчурино авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Чуаш Борнае, Югары Колчурино һәм Иске Карата авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Түбән Колчурино авылыннан 700 м көнчыгышта урнашкан 30 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньякка таба 850 м, көньяк-көнбатышка таба 650 м бара, алга таба 1,6 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 450 м урман полосасы буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, күлне кисеп үтеп, 100 м сазлык буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 200 м Түбән Әлки – Чуаш Борнае – Югары Колчурино автомобиль юлына бүлеп бирелгән

полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң көньякка таба, сынык сызык ясап, 1,2 км «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Черная Речка участок урманчылыгындагы 35 нче, 37 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 2,0 км 37 нче, 36 нчы урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 600 м 36 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 3,2 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасы буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, канауны кисеп үтеп, 1,3 км 23 нче, 22 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш һәм көньяк чикләре буйлап бара, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм көньякка таба 800 м уза, 150 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 100 м 93 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап бара, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 1,0 км 26 нчы, 27 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 550 м 27 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап бара, шуннан соң көнбатышка таба 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 600 м 27 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 27 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап һәм 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 300 м 27 нче урман кварталының көньяк һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап бара, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 27 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, сынык сызык ясап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 27 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 27 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап һәм 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр уза, 50 м шушы инеш агымы буенча аска таба Чуаш Борнае, Югары Колчурино авыл җирлекләре һәм Спас муниципаль районы чикләре тоташкан урында Юксыл авылыннан 2,5 км көньяк-көнбатышта урнашкан 28 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Чуаш Борнае авыл җирлеге чиге Иске Карата авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Чуаш Борнае, Иске Карата һәм

Чуаш Кичүе авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Иске Карата авылыннан 3,1 км көньякта урнашкан 31 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 1,9 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Түбән Әлки – Чуаш Борнае – Югары Колчурино автомобиль юлына кадәр уза, көньяк-көнбатышка таба 50 м шушы автомобиль юлы буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Борнай елгасына кадәр бара, шушы елга агымы буенча аска таба 1,0 км уза, шуннан соң Инча елгасы агымы буенча өскә таба 2,0 км бара, аннары, Сиктерме-Хузангай авылына килүче автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 1,5 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң көнбатышка таба 1,1 км урман полосасының көньяк чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 30 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Чуаш Борнае авыл җирлеге чиге Чуаш Кичүе авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Чуаш Борнае, Чуаш Кичүе һәм Түбән Кәчи авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Йолдыз поселогыннан 600 м көньяк-көнбатышта урнашкан 38 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба 1,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 3,8 км, сынык сызык ясап, «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Черная Речка участок урманчылыгындагы 42, 39, 40 нчы урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 2,2 км 40 нчы, 39 нчы урман кварталларының төньяк һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 38 нче урман кварталының көнчыгыш һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап 950 м уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 800 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 31 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Чуаш Борнае авыл җирлеге чиге Түбән Кәчи авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Чуаш Борнае, Түбән Кәчи һәм Чиябаш авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Татар Чиябашы авылыннан 1,9 км төньякта урнашкан 39 нчы тоташу ноктасыннан алып көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 3,1 км «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең

Черная Речка участок урманчылыгындагы 67 нче, 66 нчы урман кварталларының төньяк чиге буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 650 м 59 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м 59 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 750 м, төньяк-көнчыгышка таба 550 м кибеп баручы инешкә кадәр бара, әлеге инеш агымы буенча аска таба 800 м аның Чия елгасына койган җиренә кадәр уза, 30 м шушы елга агымы буенча аска таба бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 100 м 55 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 54 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 2,7 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 38 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Чуаш Борнае авыл җирлеге чиге Чиябаш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Чуаш Борнае, Чиябаш авыл җирлекләре һәм Спас муниципаль районы чикләре тоташкан урында Зур Алан авылыннан 4,4 км көнбатышта урнашкан 29 нчы тоташу ноктасыннан алып көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Юхмачы участок урманчылыгындагы 73, 74, 75 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш һәм төньяк чикләре буйлап 2,5 км уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 450 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 200 м уза, аннары көнчыгышка таба 100 м «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Черная Речка участок урманчылыгындагы 71 нче урман кварталы буйлап, 800 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң көньякка таба 150 м 72 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап Красная Речка инешенә кадәр уза, инеш агымы буенча аска таба 1,6 км бара, аннары төньякка таба 1,5 км 72 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап уза, алга таба 70 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап көнчыгышка таба 1,1 км, сынык сызык ясап, көнчыгыш чиге буйлап төньякка таба 1,0 км бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 150 м 64 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап уза, шуннан соң төньякка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 600 м 64 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап бара, сынык сызык ясап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба, Азик инешен кисеп үтеп, 64 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 750 м бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 1,0 км 65 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба 65,

66, 67 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 3,8 км 39 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Чуаш Борнае авыл җирлеге чиге Спас муниципаль районы белән чиктәш җирдә 29 нчы тоташу ноктасыннан алып Әлки муниципаль районы чиге буйлап 28 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Әлки муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен
билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
22 нче кушымта

## Әлки муниципаль районының «Чиябаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Чиябаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Чиябаш авыл җирлеге Түбән Кәчи, Чуаш Борнае, Юхмачы авыл җирлекләре һәм Спас муниципаль районы белән чиктәш.

Чиябаш авыл җирлеге чиге Чуаш Борнае авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Чиябаш, Чуаш Борнае авыл җирлекләре һәм Спас муниципаль районы чикләре тоташкан урында Зур Алан авылыннан 4,4 км көнбатышта урнашкан 29 нчы тоташу ноктасыннан алып көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Юхмачы участок урманчылыгындагы 73, 74, 75 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш һәм төньяк чикләре буйлап 2,5 км уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 450 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 200 м уза, аннары көнчыгышка таба 100 м «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Черная Речка участок урманчылыгындагы 71 нче урман кварталы буйлап, 800 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң көньякка таба 150 м 72 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап Красная Речка инешенә кадәр уза, инеш агымы буенча аска таба 1,6 км бара, аннары төньякка таба 1,5 км 72 нче урман кварталының

көнчыгыш чиге буйлап уза, алга таба 70 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап көнчыгышка таба 1,1 км, сынык сызык ясап, көнчыгыш чиге буйлап төньякка таба 1,0 км бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 150 м 64 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап уза, шуннан соң төньякка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 600 м 64 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап бара, сынык сызык ясап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба, Азик инешен кисеп үтеп, 64 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 750 м бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 1,0 км 65 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба 65, 66, 67 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 3,8 км Чиябаш, Чуаш Борнае һәм Түбән Кәчи авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Татар Чиябашы авылыннан 1,9 км төньякта урнашкан 39 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Чиябаш авыл җирлеге чиге Түбән Кәчи авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 39 нчы тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 200 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 950 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, 1,4 км Чияташ елгасы агымы буенча аска таба уза, аның агымы буенча өскә таба 15 м бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 1,6 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Чиябаш, Түбән Кәчи һәм Юхмачы авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Түбән Кәчи авылыннан 2,4 км көньяк-көнбатышта урнашкан 37 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Чиябаш авыл җирлеге чиге Юхмачы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 37 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, Юхмачы – Татар Чиябашы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 3,6 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м үләт чокырының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 850 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң көньякка таба 950 м урман полосасының көнбатыш чиге буйлап, елганың сулъяк текә ярын кисеп үтеп, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Юхмачы елгасына кадәр бара, әлеге елга агымы буенча өскә таба 2,5 км буага кадәр бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 50 м буаның уңъяк яры буйлап, 2,3 км яңадан Юхмачы елгасы агымы буенча өскә таба Чиябаш, Юхмачы авыл җирлекләре һәм Спас муниципаль районы чикләре тоташкан урында Югары Әлморза

авылыннан 3,9 км көнбатышта урнашкан 40 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Чиябаш авыл җирлеге чиге Спас муниципаль районы белән чиктәш җирдә 40 нчы тоташу ноктасыннан алып Әлки муниципаль районы чиге буйлап 29 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

«Әлки муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен
билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
23 нче кушымта

## Әлки муниципаль районының «Юхмачы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Юхмачы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Юхмачы авыл җирлеге Аппак, Түбән Кәчи, Чуаш Кичүе, Чиябаш авыл җирлекләре, Нурлат, Спас муниципаль районнары һәм Ульяновск өлкәсе белән чиктәш.

Юхмачы авыл җирлеге чиге Чиябаш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Юхмачы, Чиябаш һәм Түбән Кәчи авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Түбән Кәчи авылыннан 2,4 км көньяк-көнбатышта урнашкан 37 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, Юхмачы – Татар Чиябашы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 3,6 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м үләт чокырының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 850 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң көньякка таба 950 м урман полосасының көнбатыш чиге буйлап, елганың сулъяк текә ярын кисеп үтеп, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Юхмачы елгасына кадәр бара, әлеге елга агымы буенча өскә таба 2,5 км буага кадәр бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 50 м буаның уңъяк яры буйлап, 2,3 км яңадан Юхмачы елгасы агымы буенча өскә таба Юхмачы, Чиябаш авыл җирлекләре һәм Спас муниципаль районы чикләре тоташкан

урында Югары Әлморза авылыннан 3,9 км көнбатышта әлеге елгада урнашкан 40 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Юхмачы авыл җирлеге чиге Түбән Кәчи авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 37 нче тоташу ноктасыннан алып көнчыгышка таба 2,0 км урман полосасының төньяк чиге буйлап, Алексеевск – Югары Колок автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 500 м урман полосасы буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман полосасының төньяк чиге буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 1,5 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м сазлык буйлап Юхмачы, Түбән Кәчи һәм Чуаш Кичүе авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Юхмачы авылыннан 2,4 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 36 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Юхмачы авыл җирлеге чиге Чуаш Кичүе авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Юхмачы, Чуаш Кичүе авыл җирлекләре һәм Нурлат муниципаль районы чикләре тоташкан урында Юхмачы авылыннан 1,6 км көнчыгышта урнашкан 35 нче тоташу ноктасыннан алып 150 м Кече Чирмешән елгасы агымы буенча өскә таба бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 100 м сазлык буйлап уза, шуннан соң төньякка таба 1,3 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м сазлык буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м сазлык буйлап 36 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Юхмачы авыл җирлеге чиге Нурлат муниципаль районы белән чиктәш җирдә 35 нче тоташу ноктасыннан алып Әлки муниципаль районы чиге буйлап Юхмачы, Аппак авыл җирлекләре һәм Нурлат муниципаль районы чикләре тоташкан урында Каракүл авылыннан 1,6 км төньякта урнашкан 43 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Юхмачы авыл җирлеге чиге Аппак авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Юхмачы, Аппак авыл җирлекләре һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Аппак авылыннан 4,6 км көнбатышта урнашкан 42 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 200 м «Әлки урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Юхмачы участок урманчылыгындагы 161 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары төньякка таба 1,6 км 161 нче, 158 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң көнчыгышка таба 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м 154 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 750 м, сынык сызык ясап, 154 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң көнчыгышка таба 800 м 155 нче

урман кварталының көньяк чиге буйлап бара, аннары төньякка таба 1,9 км 155 нче, 147 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 600 м 137 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 137 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,9 км 138 нче, 139 нчы урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, көнчыгышка таба 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 800 м 139 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләре буйлап уза, аннары көнчыгышка таба 350 м урман полосасының төньяк чиге буйлап, Алексеевск – Югары Колок автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасының төньяк чиге буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м сазлык буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м сазлыкның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 150 м сазлык буйлап, 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 10 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 43 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Юхмачы авыл җирлеге чиге Ульяновск өлкәсе белән чиктәш җирдә 42 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Юхмачы авыл җирлеге, Спас муниципаль районы һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Мулланур Вахитов исемендәге авылдан 8,3 км көньяк-көнбатышта урнашкан 41 нче (2 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Юхмачы авыл җирлеге чиге Спас муниципаль районы белән чиктәш җирдә 41 нче (2 нче) тоташу ноктасыннан алып 40 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 21 ноябре
№ 96-ТРЗ

## 1199. «Саба муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 30 октябрендә
кабул ителде

### 1 статья

«Саба муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 38-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (III өлеш); 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 5 (I өлеш), 2 – 22 кушымталарны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«Саба муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль
берәмлекләрнең территорияләре чикләрен
билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
2 нче кушымта

### «Саба муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Саба муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Саба муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Саба муниципаль районы Арча, Балтач, Кукмара, Теләче муниципаль районнары белән чиктәш.

«Саба муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Саба, Арча һәм Балтач муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Мөндеш тимер юл разъезды поселогыннан 8,1 км төньяк-көнбатышта урнашкан 1 нче (50 нче) тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 750 м «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Шәмәрдән участок урманчылыгындагы 48 нче, 58 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 129 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап 500 м уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 4,7 км әлеге урманчылыктагы 58, 49, 50, 51 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 51, 60, 73, 82 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап 3,6 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м, сынык сызык ясап, көньякка таба 82 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 350 м, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 82 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 550 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м бара, 93 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 800 м, көньяк-көнбатышка таба 30 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 1,4 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасы буйлап, 200 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң 1,2 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 800 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 2,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, көньяк-көнбатышка таба 150 м үләт чокырының төньяк чиге буйлап, 550 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр бара, 1,0 км әлеге инеш агымы буенча өскә таба Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосага кадәр уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 100 м Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полоса буйлап урман полосасына кадәр бара, 150 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м урман массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң, инешне кисеп үтеп,

1,1 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 1,4 км урман полосасы буйлап бара, аннары, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны көнчыгыштан көнбатышка таба кисеп үтеп, 200 м «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Курса участок урманчылыгындагы 137 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 137, 136, 135 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 2,2 км, Чума-Елга – Курса тимер юл разъезды поселогы юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 250 м урман питомнигы буйлап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 134 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м уза, шуннан соң 134 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 250 м, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, көнбатышка таба 134 нче, 133 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап 1,1 км бара, аннары, сынык сызык ясап, 133 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 1,8 км көньяк-көнбатышка таба һәм, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 650 м көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң көнчыгышка таба 133, 134, 135 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап 1,6 км бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 100 м, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 50 м урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 135 нче урман кварталы буйлап 100 м, сынык сызык ясап, урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 400 м, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньякка таба 30 м, төньяк-көнбатышка таба 50 м Чума-Елга – Курса тимер юл разъезды поселогы автомобиль юлы буйлап уза, шуннан соң, Чума-Елга – Курса тимер юл разъезды поселогы автомобиль юлын кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 100 м урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 300 м урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, көньяк-көнбатышка таба 100 м Сүлә – Курса тимер юл разъезды поселогы автомобиль юлы буйлап, көньяк-көнчыгышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, көньяк-көнбатышка таба 50 м урман массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап,

100 м урман массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 100 м урман массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 400 м урман массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 141 нче урман кварталы буйлап 50 м, сынык сызык ясап, 200 м урман массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, сынык сызык ясап, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, төньяк-көнчыгышка таба 50 м Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 550 м урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, көнбатышка таба 1,6 км 141, 140, 139 нчы урман кварталларының төньяк чиге буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба 139 нчы, 144 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап 2,6 км, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 350 м көньяк-көнчыгышка таба 144, 149, 150 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, 200 м әлеге тимер юлга бүлеп бирелгән полосаның көньяк чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң, Байлар Сабасы — Тимершык — Югары Симет — Алан автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 2,8 км һәм төньяк-көнчыгышка таба 200 м бара, аннары 400 м көньяк-көнчыгышка таба урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң, инешне кисеп үтеп, 163 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 1,0 км, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба 4,3 км «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Курса участок урманчылыгындагы 164, 168, 167, 166 нчы урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап Саба, Арча һәм Теләче муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Югары Симет авылыннан 5,9 км көньяк-көнбатышта урнашкан 21 нче (49 нчы) тоташу ноктасына кадәр бара.

«Саба муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Саба, Балтач һәм Кукмара муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Кырбаш авылыннан 7,3 км төньяк-көнбатышта «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Шәмәрдән участок урманчылыгындагы 33 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш почмагында урнашкан 2 нче (51 нче) тоташу ноктасыннан алып әлеге урманчылыкның 40, 49, 48 нче урман кварталларының төньяк-

көнбатыш чиге буйлап 4,0 км көньяк-көнбатышка таба 1 нче (50 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Саба муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 2 нче (51 нче) тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, 12,0 км көньяк-көнчыгышка таба «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Шәмәрдән участок урманчылыгындагы 40, 41, 52, 62, 69, 70 нче урман кварталларының көнчыгыш һәм төньяк чикләре буйлап һәм 71 нче, 72 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап уза, алга таба, Балтач — Шәмәрдән автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м көнчыгышка таба һәм, сынык сызык ясап, 150 м төньяк-көнчыгышка таба бара, 400 м 80 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 1,1 км көньяк-көнчыгышка таба 80 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, Шәмәрдән авылын әйләнеп уза торган автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 89 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 900 м һәм 1,0 км көньякка таба көнчыгыш чиге буйлап, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, алга таба, сынык сызык ясап, инешне кисеп үтеп, 3,1 км көнчыгышка таба 104, 105, 106 нчы урман кварталларының төньяк һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап уза, аннары, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 2,9 км төньяк-көнчыгышка таба 106, 99, 92, 90, 81 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, алга таба, сынык сызык ясап, 450 м көнчыгышка таба 81 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап, 1,4 км көньяк-көнчыгышка таба 81 нче, 91 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,9 км көньяк-көнбатышка таба 91 нче, 92 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары 250 м төньяк-көнбатышка таба 92 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап бара, алга таба, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны төньяктан көньякка таба кисеп үтеп, 50 м көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м көньяк-көнбатышка таба урман массивы буйлап уза, алга таба 800 м көньяк-көнчыгышка таба 108 нче урман кварталы буйлап, сынык сызык ясап, 1,5 км төньяк-көнчыгышка таба, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны көньяктан төньякка таба кисеп үтеп, 101 нче, 100 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,7 км көньяк-көнчыгышка таба 100 нче, 101 нче урман кварталлары-

ның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, 1,6 км Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары 100 м көньякка таба, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,3 км 111 нче, 117 нче урман кварталларының көнчыгыш һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап бара, алга таба 1,4 км көнчыгышка таба 117, 118, 119 нчы урман кварталларының төньяк-көнчыгыш һәм төньяк чикләре буйлап уза, аннары 1,4 км көньяк-көнчыгышка таба 119 нчы, 124 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, Лесхоз – Иштуган һәм Яулаштау – Кызыл Чәчәк автомобиль юлларына бүлеп бирелгән полосаларны кисеп үтеп, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м агач-куак массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 900 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 600 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, алга таба 1,0 км төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары, инешне кисеп үтеп, 2,6 км көньяк-көнчыгышка таба «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Мишәбаш участок урманчылыгындагы 201, 204, 205 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Мишә елгасын кисеп үтеп, 350 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 550 м көньяк-көнчыгышка таба «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Сабабаш участок урманчылыгындагы 209 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 550 м көньяк-көнчыгышка таба, кибеп баручы инешләрне кисеп үтеп, 550 м төньяк-көнбатышка таба, 650 м көнчыгышка таба, Лесхоз – Иштуган автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Мишәбаш участок урманчылыгындагы 210 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,1 км 211 нче, 212 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап бара, алга таба, сынык сызык ясап, 1,9 км көньяк-көнчыгышка таба 212 нче, 219 нчы урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары 250 м көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба 1,0 км көньяк-көнчыгышка таба 220 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,0 км көньякка таба 220 нче, 229 нчы урман квар-

